**Казан шәһәре Башкарма комитетының
2025 елның 21 ноябрендәге 4094 номерлы карары**

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2010 елның 13 декабрендәге 11154 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының вазифаи затлары арасында вәкаләтләрне бүлү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Казан шәһәре Башкарма комитеты вазифаи затларының функциональ бурычларын тиешле тәртипкә китерү максатыннан карар бирәм:

1.Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 13 декабрендәге 11154 номерлы «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының вазифаи затлары арасында вәкаләтләрне бүлү турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 6 маендагы 2372 номерлы, 2011 елның 17 маендагы 2586 номерлы, 2011 елның 10 июнендәге 3134 номерлы, 2012 елның 11 мартындагы 1253 номерлы, 2012 елның 30 июлендәге 5240 номерлы, 2013 елның 4 февралендәге 1036 номерлы, 2013 елның 8 апрелендәге 3468 номерлы, 2013 елның 17 июнендәге 5808 номерлы, 2013 елның 20 декабрендәге 11222 номерлы, 2014 елның 9 гыйнварындагы 14 номерлы, 2014 елның 16 апрелендәге 2032 номерлы, 2014 елның 14 маендагы 2613 номерлы, 2014 елның 24 июнендәге 3438 номерлы, 2014 елның 5 сентябрендәге 5324 номерлы, 2014 елның 17 сентябрендәге 5472 номерлы, 2015 елның 16 мартындагы 1517 номерлы, 2015 елның 23 июлендәге 2836 номерлы, 2015 елның 30 октябрендәге 3798 номерлы, 2016 елның 1 мартындагы 731 номерлы, 2016 елның 18 апрелендәге 1651 номерлы, 2016 елның 21 июнендәге 2501 номерлы, 2016 елның 1 июлендәге 2671 номерлы, 2016 елның 1 августындагы 3011 номерлы, 2016 елның 31 августындагы 3674 номерлы, 2016 елның 4 октябрендәге 3950 номерлы, 2016 елның 7 декабрендәге 4989 номерлы,

2017 елның 10 мартындагы 624 номерлы, 2017 елның 15 маендагы 1747 номерлы, 2017 елның 2 июнендәге 2053 номерлы, 2017 елның 9 июнендәге 2175 номерлы, 2017 елның 16 июнендәге 2206 номерлы, 2017 елның 14 июлендәге 2643 номерлы, 2017 елның 7 сентябрендәге 3540 номерлы, 2017 елның 27 сентябрендәге 3805 номерлы, 2017 елның 9 ноябрендәге 4565 номерлы, 2018 елның 16 апрелендәге 1409 номерлы, 2018 елның 11 маендагы 2146 номерлы, 2018 елның 22 июнендәге 3655 номерлы, 2018 елның 9 августындагы 4424 номерлы, 2018 елның 16 октябрендәге 5374 номерлы, 2019 елның 8 февралендәге 435 номерлы, 2019 елның 26 июлендәге 2716 номерлы, 2019 елның 7 августындагы 2834 номерлы, 2019 елның 19 сентябрендәге 3362 номерлы, 2019 елның 25 октябрендәге 3912 номерлы, 2019 елның 21 ноябрендәге 4156 номерлы, 2021 елның 4 февралендәге 252 номерлы, 2021 елның 12 февралендәге 329 номерлы, 2021 елның 26 февралендәге 474 номерлы, 2021 елның 9 мартындагы 520 номерлы, 2021 елның 29 мартындагы 729 номерлы, 2021 елның 13 апрелендәге 857 номерлы, 2021 елның 16 апрелендәге 895 номерлы, 2021 елның 19 августындагы 2078 номерлы, 2021 елның 1 октябрендәге 2505 номерлы, 2021 елның 10 декабрендәге 3280 номерлы, 2021 елның 22 декабрендәге 3444 номерлы, 2022 елның 10 мартындагы 690 номерлы, 2022 елның 24 маендагы 1511 номерлы, 2022 елның 17 октябрендәге 3527 номерлы, 2023 елның 24 июлендәге 2073 номерлы, 2024 елның 31 маендагы 2277 номерлы, 2024 елның 15 августындагы 3365 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2010 елның 13 декабрендәге 11154 номерлы карарына кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 21 ноябрендәге
4094 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**вазифаи затлары арасында вәкаләтләрне бүлү турында**
**нигезләмә**

Казан шәһәре Башкарма комитетының вазифаи затлары арасында вәкаләтләрне бүлү турында нигезләмә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге уставы (алга таба – Устав), Казан шәһәре Башкарма комитеты структурасы (алга таба – Башкарма комитет структурасы), Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты структурасы (алга таба – Башкарма комитет Аппараты структурасы) нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитетының (алга таба – Башкарма комитет) һәм аның вазифаи затларының Казан шәһәренең җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрен хәл итү, законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча идарә эшчәнлеген оптимальләштерү максатыннан раслана.

## I. Башкарма комитетның вазифаи затлары

Устав, Башкарма комитет структурасы һәм Башкарма комитет Аппараты структурасы нигезендә Башкарма комитетның җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү һәм Башкарма комитет, аның структур бүлекчәләре эшчәнлеген оештыру буенча үз башкару-боеру вәкаләтләренә ия булган вазифаи затлары түбәндәгеләр:

- Башкарма комитет Җитәкчесе;
- Башкарма комитет Җитәкчесенең шәһәр төзелеше сәясәте мәсьәләләре буенча беренче урынбасары;
- Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль өлкә мәсьәләләре буенча урынбасары;
- Башкарма комитет Җитәкчесенең торак-коммуналь хуҗалык һәм гражданнарны яклау мәсьәләләре буенча урынбасары;
- Башкарма комитет Җитәкчесенең төзекләндерү мәсьәләләре буенча урынбасары;

- Башкарма комитет Җитәкчесенең транспорт, икътисади үсеш һәм сәүдә мәсьәләләре буенча урынбасары;

- Башкарма комитет Аппараты җитәкчесе;

- Башкарма комитетның районнар администрацияләре башлыклары;

- Башкарма комитетның «Иске шәһәр» территориясе префекты;

- Башкарма комитет органнары җитәкчеләре.

## II. Башкарма комитет Җитәкчесенең җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләре

2.1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүне оештыру максатыннан Башкарма комитет Җитәкчесенә түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

2.1.1. Казан шәһәре бюджеты проектын эшләүне оештыру, аны, кирәкле документларны һәм материалларны Казан шәһәре Думасына раслауга кертү;

2.1.2. бюджет үтәлешен, шул исәптән бюджет керемнәрен җыюны, муниципаль бурыч белән идарә итүне, бюджет үтәлеше буенча ведомство контролен оештыру;

2.1.3. Казан шәһәре бюджеты үтәлешен координацияләү;

2.1.4. Казан шәһәре бюджеты үтәлешен һәм бюджет акчаларын төп бүлүчеләр, бүлүчеләр һәм алучылар тарафыннан бюджет акчаларын файдалануны беренчел, агымдагы һәм алга таба контрольдә тотуны оештыру;

2.1.5. бюджет үтәлеше турында хисап әзерләүне оештыру, аны Казан шәһәре Думасына раслауга кертү;

2.1.6. Казан шәһәре Мэры белән килештереп, Башкарма комитетның вазифаи затларын вазифага билгеләү һәм вазифадан азат итү;

2.1.7. Башкарма комитетның һәм Башкарма комитет Аппаратының структур бүлекчәләре җитәкчеләрен билгеләү;

2.1.8. муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләрен, муниципаль хезмәткәрләрне, Казан шәһәренең баш архитекторын эшкә билгеләү тәртибен ачыклау;

2.1.9. җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару, җирле бюджет акчаларыннан чыгымнар тоту мәсьәләләре буенча норматив хокукый акт проектларын Казан шәһәре Думасына карап тикшерүгә кертү һәм, хокукый иҗат инициативасының башка субъектлары тарафыннан кертелгәндә, мондый норматив хокукый актлар проектларын килештерү;

2.1.10. муниципаль эчке хисаплашуларны гамәлгә ашыру, кредит килешүләрен һәм шартнамәләрен, Казан шәһәре бюджетының бердәм счетында калган акчаларны тулыландыруга Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә бюджет кредиты бирү турында шартнамәләр, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм (яисә) Башкарма комитет исеменнән инвестиция, концессия һәм башка килешүләр (шартнамәләр) төзү;

2.1.11. Казан шәһәре бюджетының бердәм счетында калган акчаларны тулыландыруга бюджет кредиты бирү турындагы шартнамә шартларын тиешенчә үтәүне тәэмин итү;

2.1.12. Казан шәһәре бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирү;

2.1.13. тиешле елга шәһәр бюджеты турында карарда билгеләнгән чикләрдә муниципаль гарантияләр бирү;

2.1.14. Россия Федерациясе Бюджет кодексы, бюджет законнарының башка хокукый актлары, Казан шәһәре Думасы актлары белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

2.1.15. шәһәрнең социаль-икътисади яктан үсеш планнары һәм программалары проектларын эшләүне оештыру, аларны Казан шәһәре Думасына раслауга кертү, аларның үтәлешен оештыру;

2.1.16. җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару, законнар нигезендә җирле салымнар һәм җыемнар буенча ташламалар билгеләү турында карар проектларын әзерләүне оештыру һәм аларны Казан шәһәре Думасына раслауга кертү;

2.1.17. Казан шәһәре муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре товарларына, эшләренә һәм хезмәтләренә тарифлар, бәяләр билгеләү;

2.1.18. коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәтләренә тарифларны, коммуналь инфраструктура системаларына тоташтыруга тарифларны, оешмалар товарлары һәм хезмәтләре тарифларына өстәмәләрне җайга салуны гамәлгә ашыру;

2.1.19. торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарында наем шартнамәләре буенча түләп торучылар өчен торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урыннар хуҗалары өчен, шулай ук гомуми җыелышта мондый түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннар хуҗалары өчен торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен билгеләү;

2.1.20. товарларына, хезмәтләренә бәяләр (тарифлар) җайга салынырга тиешле коммуналь комплекс оешмаларының энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге программаларына карата таләпләрне билгеләү;

2.1.21. җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген, җирле әһәмияткә ия гомуми файдалануда булмаган автомобиль юллары исемлеген раслау;

2.1.22. юл сервисы объектларын җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына тоташтыру хезмәтләренең бәясен һәм исемлеген билгеләү;

2.1.23. җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын капиталь ремонтлауга, агымдагы ремонтлауга, карап тотуга финанс чыгымнары нормативларын һәм күрсәтелгән максатларга җирле бюджеттан бүленә торган ассигнованиеләр күләмен исәпләү кагыйдәләрен раслау;

2.1.24. җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан, автомобиль юллары участокларыннан түләүле нигездә файдалану һәм бу рәвешле файдалануны туктату турында карарлар кабул итү;

2.1.25. Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертү яки аны туктату турында карар кабул итү;

2.1.26. шәһәрнең муниципаль милке белән идарә итү, муниципаль милек объектларын булдыру, сатып алу, алардан файдалану мәсьәләләре буенча карарлар кабул итү;

2.1.27. коррупциягә каршы көрәш чараларын оештыру;

2.1.28. муниципаль объектлар төзелешенә заказ бирүчеләрне билгеләү;

2.1.29. муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне төзү, үзгәртеп кору һәм ябу турында карарлар кабул итү, әлеге нигезләмәгә таянып, җитәкчеләрне вазифага билгеләү һәм азат итү вәкаләтләре бүтән вазифаи затларга тапшырылудан тыш, аларның җитәкчеләрен вазифага билгеләү һәм вазифадан азат итү турында карарлар кабул итү;

2.1.30. коммерциягә нигезләнмәгән автоном оешмалар һәм фондлар рәвешендә коммерциягә нигезләнмәгән оешмалар төзү турында, шулай ук ябык акционерлык җәмгыятьләре һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр рәвешендә муниципальара хуҗалык җәмгыятьләрен гамәлгә кую турында карарлар кабул итү;

2.1.31. гамәлдәге законнар һәм Казан шәһәре Думасының хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә муниципаль милекне хосусыйлаштыру буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

2.1.32. муниципаль милеккә караган җирләрдән файдалануны планлаштыруны оештыру;

2.1.33. җир кишәрлекләрен территорияләрнең кадастр планнарында урнаштыру схемаларын раслау;

2.1.34. Казан шәһәре җирләрен инвентаризацияләү, мониторинглау буенча җирле программаларны раслау;

2.1.35. муниципаль ихтыяҗлар өчен шәһәр чикләрендә, шул исәптән сатып алу юлы белән җир кишәрлекләрен алу турында карар кабул итү, шәһәр җирләреннән файдалануны контрольдә тотуны оештыру;

2.1.36. аз керемле гражданнарга социаль наем шартнамәләре нигезендә муниципаль торак фондыннан торак урыннар бирү турында карарлар кабул итү, социаль наем шартнамәләре нигезендә торак урыннар алуга мохтаҗлар исемлекләрен раслау;

2.1.37. реклама мәгълүматын урнаштыру өлкәсендә кагыйдәләр билгеләү;

2.1.38. шәһәр дәрәҗәсендәге әһәмияткә ия су ресурсларын файдалануга бирү турында карар кабул итү;

2.1.39. җир кишәрлекләрен яки билгеләнгән тәртиптә җир кишәрлекләрен арендалауга шартнамәләр төзү хокукын сату буенча сатулар (аукционнар, конкурслар) оештыру;

2.1.40. гамәлдәге законнар белән каралган хокукларда һәм максатларда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Генераль планы, расланган шәһәр төзелеше документлары нигезендә җир кишәрлекләрен бирү турында карарлар кабул итү;

2.1.41. шәһәр территориясендә җир төзелеше турында карар кабул итү;

2.1.42. муниципаль милектәге җирләрдән гражданнарга шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару һәм шәхси торак төзелеше өчен милеккә бирелә торган җир кишәрлекләренең чик (максималь һәм минималь) күләмнәрен билгеләүдә катнашу;

2.1.43. гражданнарны аз керемле дип тану максатыннан гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган керем күләмен һәм гаилә әгъзалары милкендә булган мөлкәт хакын билгеләү;

2.1.44. урам исемнәрен билгеләү;

2.1.45. халыкны кабул итүне оештыру, шулай ук гражданнарның шикаятьләрен, гаризаларын һәм тәкъдимнәрен карап тикшерү, алар буенча үз вәкаләтләре кысаларында кирәкле чаралар күрү;

2.1.46. җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төрләренә һәм капиталь төзелеш объектларына карата рөхсәт ителгән төзелешнең һәм аларны реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү;

2.1.47. муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын үтәү, Башкарма комитетның структур бүлекчәләре вәкаләтләренә караган мәсьәләләрне хәл итү буенча эшне оештыру өлешендә эшчәнлекне контрольдә тоту һәм координацияләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

2.1.48. шәһәр чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү эшен координацияләү;

2.1.49. халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендәге эшне законнар нигезендә координацияләү;

2.1.50. гражданнар оборонасы өлкәсендә эшне координацияләү һәм территориаль оборонаны планлаштыруда катнашу;

2.1.51. Казан шәһәре чикләрендә террорчылык һәм экстремизмны кисәтү өлкәсендә, шулай ук террорчылык һәм экстремизм күренешләренең нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү өлкәсендә эшне координацияләү;

2.1.52. Башкарма комитетта мобилизация әзерлеген оештыру;

2.1.53. Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының идарә һәм элемтәнең техник чараларын кулланугa даими әзерлектә тотуны, шулай ук халыкны элемтә хезмәтләре белән тотрыклы тәэмин итүне контрольдә тотуны оештыру;

2.1.54. Казан шәһәре җирле үзидарә органнарында дәүләт серен саклау чараларын оештыру һәм контрольдә тоту;

2.1.55. Казан шәһәре бюджетына күчерелергә тиешле салымнарны түләү вакытын чираттагы финанс елына Казан шәһәре Думасы карары белән билгеләнгән кичектереп түләү, ваклап түләү һәм салым кредитлары лимитлары чикләрендә кичектереп түләү, ваклап түләү, салым кредиты, салым инвестиция кредиты рәвешендә үзгәртү турында салым органнары карарларын килештерү;

2.1.56. устав капиталындагы акцияләре (өлешләре) муниципаль милектә булган хуҗалык җәмгыятьләре акционерының (анда катнашучының) хокукларын гамәлгә ашыруны оештыру;

2.1.57. Башкарма комитет өчен Устав, Казан шәһәре Думасының хокукый актлары белән билгеләнгән башка вәкаләтләрне, шулай ук җирле үзидарә органнары, җирле администрация башлыгы, җирле администрация өчен

гамәлдәге законнар белән билгеләнгән һәм җирле үзидарәнең вәкиллекле органы вәкаләтләренә керми торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.

2.2. Әлеге нигезләмәнең 2.1 пунктында күрсәтелгән мәсьәләләр буенча Башкарма комитет Җитәкчесе муниципаль хокукый актлар – карарлар һәм боерыклар кабул итәргә, законнар нигезендә, башка документларны имзаларга хокуклы.

2.3. Башкарма комитет Җитәкчесе үз вәкаләтләре кысаларында Башкарма комитетның Финанс идарәсе, Башкарма комитетның Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты, «Казан шәһәренең социаль өлкә учреждениеләрен карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе, «Казан шәһәренең муниципаль учреждениеләренә бухгалтерлык хезмәте күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе эшен контрольдә тота.

2.4. Башкарма комитет Җитәкчесе урында булмаган вакытта аның вәкаләтләрен башкару, Казан шәһәре Мэры боерыгы нигезендә, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасарына яки урынбасарларының берсенә, Башкарма комитет Аппараты җитәкчесенә йөкләнә.

## III. Башкарма комитет Җитәкчесенең шәһәр төзелеше сәясәте мәсьәләләре буенча беренче урынбасары вәкаләтләре

3.1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүне оештыру максатыннан Башкарма комитет Җитәкчесенең шәһәр төзелеше сәясәте мәсьәләләре буенча беренче урынбасарына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

3.1.1. шәһәр бюджеты акчалары хисабына муниципаль торак йортлар, коммуналь хуҗалык объектлары төзелешен оештыру;

3.1.2. Казан шәһәре территориясендә урнашкан капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, аларга капиталь ремонт үткәрелгәндә төзелешкә, объектларны файдалануга тапшыруга рөхсәтләрне имзалау һәм аларны бирүне оештыру;

3.1.3. җирле әһәмияткә ия җир асты корылмаларын төзүгә билгеләнгән тәртиптә рөхсәтләр бирү;

3.1.4. җирле бюджет акчалары хисабына гамәлгә ашырыла торган төзелешләрнең проектларын һәм титул исемлекләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту;

3.1.5. юл хуҗалыгы өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү һәм дәүләт милке белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыра торган федераль башкарма

хакимият органына автомобиль юлларын файдалануга тапшыру яки, Автомобиль юлларының бердәм дәүләт реестрына кертү өчен, автомобиль юллары турындагы белешмәләрнең үзгәрүе хакында мәгълүмат бирү эшен оештыру;

3.1.6. үз вәкаләтләре кысаларында халыкны кабул итүне оештыру, шулай ук гражданнарның шикаятьләрен, гаризаларын һәм тәкъдимнәрен карап тикшерү, алар буенча кирәкле чаралар күрү;

3.1.7. коррупциягә каршы көрәш чараларын оештыру;

3.1.8. муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын үтәү, әлеге нигезләмәнең 3.2 пунктында китерелгән Башкарма комитетның структур бүлекчәләре вәкаләтләренә караган мәсьәләләрне хәл иткәндә эшне оештыру өлешендә эшчәнлекне контрольдә тоту һәм координацияләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

3.1.9. шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә документларны эшләүгә билгеләнгән тәртиптә йөкләмәләр бирүне оештыру;

3.1.10. гамәлдәге төзелеш планын (терәк һәм адреслы планнарны), корылмаларны, элемтә коммуникацияләрен һәм линия җиһазларын урнаштыруның теркәү планын алып баруны оештыру;

3.1.11. җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләренә һәм рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрларыннан тайпылуга, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә рөхсәт бирүне оештыру яисә, кабул ителгән карарның сәбәпләрен күрсәтеп, мондый рөхсәтләр бирүне кире кагу турында белешмәләр тапшыруны оештыру;

3.1.12. территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектларын муниципаль хокукый актларны, башка рәсми мәгълүматны рәсми бастырып чыгару өчен каралган тәртиптә бастырып чыгаруны һәм югарыда күрсәтелгән мәгълүматны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында урнаштыруны оештыру;

3.1.13. Казан шәһәрендә ачык сервитутлар турында документлар әзерләүдә катнашуны оештыру;

3.1.14. җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләүне һәм бирүне оештыру;

3.1.15. шәһәрнең генераль планын, территорияләрне планлаштыру һәм ызанлау проектларын, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен, шәһәрнең инженерлык корылмалары һәм төзекләндерү проектларын, шулай ук шәһәр төзелеше законнары белән каралган башка документларны эшләүне оештыру;

3.1.16. күчемсез милек объектларына адрес номерлары бирү;

3.1.17. шәһәрне шәһәр төзелеше буенча проектлаштыруның җирле нормативларын эшләүне оештыру;

3.1.18. шәһәр территориясендә урнашкан һәм архитектура ягыннан кыйммәте булган объектларны архитектура һәйкәлләре дип игълан итү турында Башкарма комитет исеменнән тиешле органнарга тәкъдимнәр кертү;

3.1.19. Казан шәһәре милкендә булган мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрне) саклауны, файдалануны һәм популярлаштыруны, Казан шәһәре территориясендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният һәйкәлләрен) саклауны оештыру;

3.1.20. шәһәр төзелеше һәм проект документлары, шәһәр территориясен архитектура-сәнгать ягыннан бизәү һәм төзекләндерү проектлары буенча иң яхшы эшләргә конкурслар үткәрүне оештыру;

3.1.21. җир кишәрлекләре ясау эшен оештыру;

3.1.22. шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны җыю, документлаштыру, актуальләштерү, эшкәртү, системалаштыру, исәпкә алу һәм саклау юлы белән шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасын алып баруны оештыру;

3.1.23. шәһәрнең Генераль планы нигезендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләүне оештыру, Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү һәм аларны, раслау өчен, Казан шәһәре Думасына тапшыру;

3.1.24. Казан шәһәре Башкарма комитетына Казан шәһәре чикләрендәге җирләрне резервлау һәм җир кишәрлекләрен муниципаль ихтыяҗлар өчен алу турында тәкъдимнәр кертү;

3.1.25. Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан үткәрелә торган мобилизация әзерлеге чараларында катнашу;

3.1.26. шәһәр яңы зонасында Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының эшче төркеме эшчәнлеген оештыру һәм тәэмин итү;

3.1.27. гражданнар оборонасының сак корылмалары төзелешен координацияләү;

3.1.28. дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматларның яшеренлек һәм аларны саклау режимы таләпләрен үтәүне тәэмин итү;

3.1.29. дәүләт серенә рөхсәт бирү турында карар кабул иткән җитәкче белән чит илгә чыгуны билгеләнгән тәртиптә килештерү;

3.1.30. кул астында эшләүче хезмәткәрләрнең дәүләт серен саклау турындагы законнарны үтәвен контрольдә тотуны тәэмин итү;

3.1.31. Башкарма комитетның ведомство карамагындагы бүлекчә хезмәткәрләре белән производствода бәхетсезлек очрагы килеп чыккан вакыттан алып бер тәүлек эчендә гамәлдәге законнар һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән органнарга бу хакта хәбәр итүне тәэмин итү;

3.1.32. ясалма җир кишәрлекләрен булдыру буенча эшләрне башкаруга рөхсәтләрне имзалау һәм аларны бирүне оештыру, Казан шәһәре территориясендә урнашкан ясалма булдырылган җир кишәрлекләрен файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирүне оештыру.

3.2. Башкарма комитет Җитәкчесенең шәһәр төзелеше сәясәте мәсьәләләре буенча беренче урынбасары үз вәкаләтләре чикләрендә:

а) түбәндәгеләрнең эшен координацияли:

- Башкарма комитетның Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе;

- Башкарма комитетның Шәһәр төзелешенә рөхсәтләр бирү идарәсе;

- Башкарма комитетның Капиталь төзелеш һәм реконструкция идарәсе;

- Башкарма комитет Аппаратының төзелешне үстерү һәм координацияләү бүлеге;

б) түбәндәгеләрнең эшен контрольдә тота һәм эшчәнлекләренең нәтиҗәлелек күрсәткечләре үтәлеше өчен җавап бирә:

- «Казметрострой» акционерлык җәмгыяте;

- «Беренчел документларны әзерләү үзәге» акционерлык җәмгыяте;

- «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе;

в) үз карамагындагы предприятиеләрнең җитәкчеләрен вазифага билгеләү, алар белән хезмәт килешүләрен төзү, үзгәртү, гамәлдән чыгару, аларга карата дисциплинар җәза куллану турында тәкъдимнәр кертә;

г) үз карамагындагы муниципаль учреждениеләр җитәкчеләрен вазифага билгели һәм вазифадан азат итә, аларга карата дисциплинар җәза чараларын куллана, аларның чираттагы ялларын һәм командировкаларын килештерә;

д) түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

- Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Техник инвентаризация бюросы» республика дәүләт унитар предприятиесе;

- Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

- әлеге нигезләмәнең 3.2 пунктында күрсәтелгән структур бүлекчәләрнең вәкаләтләре өлкәсендә муниципаль контрактларны (башка килешүләрне) үтәү эшчәнлеген башкара торган оешмалар;

е) Башкарма комитет Җитәкчесе йөкләмәсе нигезендә үз эшчәнлеге юнәлеше буенча комиссияләргә җитәкчелек итә, штабларны, эшче төркемнәрне җитәкли, үз вәкаләтләре кысаларында Башкарма комитет Җитәкчесенең башка йөкләмәләрен үти.

3.3. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатыннан Башкарма комитет Җитәкчесенең шәһәр төзелеше сәясәте мәсьәләләре буенча беренче урынбасары боерыклар чыгара, шулай ук башка документларны имзалый.

## IV. Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль өлкә мәсьәләләре буенча урынбасары вәкаләтләре

4.1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүне оештыру максатыннан Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль өлкә мәсьәләләре буенча урынбасарына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

4.1.1. мәгариф, мәдәният, яшьләр сәясәте, спорт өлкәләрендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру, контрольдә тоту һәм координацияләү;

4.1.2. Казан шәһәре территориясендә мәгариф, мәдәният, спорт учреждениеләре, шулай ук балалар һәм яшьләр мәсьәләләре белән шөгыльләнә торган учреждениеләр челтәрен үстерү эшен планлаштыруны оештыру, контрольдә тоту һәм координацияләү;

4.1.3. Казан шәһәре территориясендә социаль-мәдәни билгеләнештәге объектлар төзү һәм әлеге объектларны карап тоту буенча тәкъдимнәр кертү;

4.1.4. Казан шәһәре муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен алу мөмкинлеге булган һәм бушлай мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру, контрольдә тоту һәм координацияләү (федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү вәкаләтләреннән тыш);

4.1.5. муниципаль мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирүне оештыру, контрольдә тоту һәм координацияләү (финанс яктан Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан тәэмин ителә торган өстәмә белем бирүдән тыш);

4.1.6. мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга тиешле балаларны исәпкә алуны оештыру, контрольдә тоту һәм координацияләү;

4.1.7. дәрестән тыш вакытта һәм каникул вакытларында укучыларның ялын, аларны сәламәтләндерүне, хезмәтен һәм мәшгульлеген оештыру, контрольдә тоту һәм координацияләү;

4.1.8. опека һәм попечительлек эшчәнлеген оештыру;

4.1.9. балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре эшчәнлеген оештыру;

4.1.10. балигъ булмаганнарның караучысыз калуын һәм хокук бозуларын кисәтү;

4.1.11. балигъ булмаганнарның хокук бозуларын, балаларның караучысыз калуын һәм яшьләр даирәсендә башка тискәре социаль күренешләрне кисәтү эшчәнлеген оештыру, хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый яшьләр берләшмәләренә ярдәм күрсәтү һәм аларның эшен оештыру;

4.1.12. девиант тәртипле балаларны социаль тернәкләндерү эшчәнлеген оештыру;

4.1.13. Казан шәһәрендә наркотикларга каршы комиссия эшчәнлеген һәм наркомания, тәмәке тарту, алкоголизм таралуны кисәтү буенча башка төрле эшләр оештыру;

4.1.14. халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыруны, Казан шәһәренең китапханә фондларын туплауны, аларның сакланышын тәэмин итүне координацияләү һәм контрольдә тоту;

4.1.15. Казан шәһәренең мәдәни мирас объектларын саклау эшчәнлеген оештыру;

4.1.16. Казан шәһәре халкының массакүләм ял итүе өчен шартлар тудыру эшчәнлеген оештыру;

4.1.17. җирле традицион халык сәнгате иҗатын үстерү һәм халык сәнгате һөнәрләрен саклау, торгызу һәм үстерү өчен шартлар тудыру эшчәнлеген оештыру;

4.1.18. шәһәр халкы арасында физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт эшен оештыру, үткәрү эшчәнлеген координацияләү;

4.1.19. Казан шәһәрендә спорт секцияләре, балалар түгәрәкләре һәм яшүсмерләр клублары эше өчен шартлар тудыру эшчәнлеген оештыру;

4.1.20. финанслар белән тәэмин итү мәсьәләләреннән тыш, физик тәрбия һәм спорт, мәгариф, мәдәният өлкәләрендә, яшьләрнең фәнни-техник һәм сәнгать иҗатын, балалар, яшьләр һәм гаилә ялы системасын, яшьләр арасында хәрби-патриотик эшне, су асты көймәләренә каршы кече «Казанец» корабле белән шефлык элемтәләрен үстерү буенча шәһәр программаларын һәм проектларын, шулай ук яшьләр сәясәте өлкәсендә яшьләрдә гражданлык һәм

патриотлык хисе тәрбияләүгә юнәлтелгән шәһәр программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру эшчәнлеген оештыру, контрольдә тоту һәм координацияләү;

4.1.21. муниципаль берәмлек халкына еллык статистик мәгълүматлар нигезендә муниципаль берәмлек территориясендә социаль әһәмияткә ия булган авырулар һәм әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыра торган авырулар таралу мөмкинлеге турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итү, шулай ук эпидемияләр башлану куркынычы, башлану һәм Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә статистик белешмәләр турында мәгълүмат бирү;

4.1.22. халыкның санитария-гигиена өлкәсендәге белемнәрен арттыруда, кан һәм (яки) аның компонентлары донорлыгын пропагандалауда катнашу;

4.1.23. муниципаль берәмлек территориясендә гадәттән тыш хәлләр вакытында кешеләрнең гомерен һәм сәламәтлеген саклап калуга юнәлтелгән чараларны гамәлгә ашыруда катнашу, гадәттән тыш хәл зонасында медицина һәм санитария ягыннан тәэмин ителешнең торышы һәм күрелә торган чаралар турында халыкка хәбәр итү;

4.1.24. муниципаль берәмлек территориясендә авыруларны кисәтү һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру чараларын Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә гамәлгә ашыру;

4.1.25. инвалидларның, ветераннарның һәм башка категориягә караган гражданнарның социаль инфраструктурадан, барлык төр транспорт, элемтә чараларыннан тоткарлыксыз файдалана алуы өчен шартлар тудыру буенча тәкъдимнәр кертү;

4.1.26. гражданнарның аз керемле категорияләренә адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтү эшчәнлеген оештыру;

4.1.27. социаль-хокукый ярдәм һәм реабилитацияләнгән сәяси репрессия корбаннары истәлеген мәңгеләштерү мәсьәләләре эшен координацияләү;

4.1.28. халыкны кабул итүне оештыру, шулай ук гражданнарның шикаятьләрен, гаризаларын һәм тәкъдимнәрен карап тикшерү, алар буенча үз вәкаләтләре чикләрендә кирәкле чаралар күрү;

4.1.29. коррупциягә каршы көрәш чараларын оештыру;

4.1.30. Башкарма комитет тарафыннан үткәрелә торган мобилизация әзерлеге чараларында катнашу;

4.1.31. мобилизация чорында һәм хәрби хәл вакытында мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният, физик тәрбия һәм спорт өлкәләрендә хезмәт күрсәтүне оештыру;

4.1.32. муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын үтәү, Башкарма комитетның әлеге нигезләмәнең 4.2 пунктында күрсәтелгән структур бүлекчәләре үз вәкаләтләрен башкарганда эшне оештыру өлешендә эшчәнлекне контрольдә тоту һәм координацияләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

4.1.33. Казан шәһәре территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләренә һәм мәдәниятләренә ярдәм итүне һәм аларны үстерүне оештыру;

4.1.34. террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу;

4.1.35. Башкарма комитетның структур бүлекчәләре эшчәнлеген координацияләү, Бишбалта бистәсен торгызу һәм «Аккош күле» махсус сакланыла торган табигать территориясен тернәкләндерү проектларын гамәлгә ашыруда катнаша торган федераль һәм республика оешмалары белән хезмәттәшлек итү;

4.1.36. үз карамагындагы муниципаль учреждениеләр эшчәнлеген координацияләү, аларны матди-техник яктан тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүдә булышлык күрсәтү;

4.1.37. үз карамагындагы учреждениеләрнең милке турында Башкарма комитетның Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты тарафыннан әзерләнгән документларны килештерү;

4.1.38. үз карамагындагы учреждениеләр структурасын килештерүдә катнашу;

4.1.39. үз карамагындагы бүлекчәләрнең штат расписаниесен килештерүдә катнашу;

4.1.40. үз карамагындагы учреждениеләр өчен муниципаль йөкләмә формалаштыруда һәм килештерүдә катнашу;

4.1.41. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең мәдәни кыйммәтләрен саклауны оештыру;

4.1.42. Казан шәһәре территориясендә милләтара татулыкны ныгытуга юнәлдерелгән чараларны эшләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыру;

4.1.43. дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматларның яшеренлек һәм аларны саклау режимы таләпләрен үтәүне тәэмин итү;

4.1.44. дәүләт серенә рөхсәт бирү турында карар кабул иткән җитәкче белән чит илгә чыгуны билгеләнгән тәртиптә килештерү;

4.1.45. кул астында эшләүче хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт серен саклау турындагы законнарның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;

4.1.46. Башкарма комитет карамагындагы бүлекчә хезмәткәрләре белән производствода бәхетсезлек очрагы килеп чыккан вакыттан алып бер тәүлек эчендә гамәлдәге законнар һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән органнарга бу хакта хәбәр итүне тәэмин итү.

4.2. Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль өлкә мәсьәләләре буенча урынбасары:

а) түбәндәгеләрнең эшен координацияли:

- Башкарма комитетның Мәгариф идарәсе;

- Башкарма комитетның Мәдәният идарәсе;

- Башкарма комитетның Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты;

- Башкарма комитетның Физик культура һәм спорт комитеты;

- Башкарма комитет Аппаратының социаль сәясәт идарәсе;

- Башкарма комитет Аппаратының тел культурасы өлкәсендә милли сәясәтне гамәлгә ашыру бүлеге;

б) түбәндәгеләрнең эшен контрольдә тота һәм эшчәнлекләренең нәтиҗәлелек күрсәткечләре үтәлеше өчен җавап бирә:

- мәдәният, мәгариф буенча муниципаль учреждениеләр, муниципаль автоном учреждениеләр, Башкарма комитетның Физик культура һәм спорт комитеты, Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты;

в) үз карамагындагы муниципаль учреждениеләр җитәкчеләрен вазифага билгели һәм вазифадан азат итә, аларга карата дисциплинар җәза чараларын куллана, аларның чираттагы ялларын һәм командировкаларын килештерә;

г) түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

- Россия Федерациясе Социаль фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе;

- «Казан шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе;

- әлеге нигезләмәнең 4.2 пунктында күрсәтелгән структур бүлекчәләрнең вәкаләтләре өлкәсендә муниципаль контрактларны (башка килешүләрне) үтәү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган оешмалар;

- Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;

- «12 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» акционерлык җәмгыяте;

- «АВА-Казан» акционерлык җәмгыяте;

д) Башкарма комитет Җитәкчесе йөкләмәсе нигезендә үз эшчәнлеге юнәлеше буенча комиссияләргә җитәкчелек итә, штабларны, эшче төркемнәрне

җитәкли, үз вәкаләтләре кысаларында Башкарма комитет Җитәкчесенең башка йөкләмәләрен үти.

4.3. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатыннан Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль өлкә мәсьәләләре буенча урынбасары боерыклар чыгара, шулай ук башка документларны имзалый.

## V. Башкарма комитеты Җитәкчесенең торак-коммуналь хуҗалык һәм гражданнарны саклау мәсьәләләре өчен җаваплы урынбасары вәкаләтләре

5.1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүне оештыру максатыннан Башкарма комитет Җитәкчесенең торак-коммуналь хуҗалык һәм гражданнарны яклау мәсьәләләре буенча урынбасарына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

5.1.1. торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү), социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарында наем шартнамәләре буенча түләп торучылар өчен торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урыннар хуҗалары өчен, шулай ук гомуми җыелышта мондый түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йорттагы торак урыннар хуҗалары өчен торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен билгеләү буенча Башкарма комитетның хокукый актларын әзерләүне һәм килештерүне оештыру;

5.1.2. энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә муниципаль программаларны эшләүне һәм гамәлгә ашыруны оештыру;

5.1.3. товарларына, хезмәтләренә бәяләр (тарифлар) җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнергә тиешле коммуналь комплекс оешмаларының энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендәге программаларына карата таләпләр әзерләүне оештыру;

5.1.4. муниципаль учреждениеләр, муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча чараларны координацияләү һәм әлеге чараларны үткәрүне контрольдә тоту;

5.1.5. җылыту чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләре белән билгеләнгән таләпләрне үтәүне оештыру һәм җылылык белән тәэмин итә торган оешмаларның, җылылык челтәрләре оешмаларының, кулланучыларның аерым категорияләренең җылыту чорына әзерлеген контрольдә тоту;

5.1.6. җылылык энергиясе чыганакларын, җылылык челтәрләрен ремонтка туктату һәм файдаланудан чыгаруны килештерү;

5.1.7. җылылык белән тәэмин итү схемаларын раслау, шул исәптән җылылык белән тәэмин итә торган бердәм оешманы билгеләү;

5.1.8. җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салына торган төрләрен гамәлгә ашыручы оешмаларның инвестиция программаларын Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә килештерү;

5.1.9. шәһәр территориясендә җәмәгать эшләрен оештыру;

5.1.10. үз вәкаләтләре кысаларында халыкны кабул итүне оештыру, шулай ук гражданнарның шикаятьләрен, гаризаларын һәм тәкъдимнәрен карап тикшерү, алар буенча кирәкле чаралар күрү;

5.1.11. Казан шәһәре территориясендә торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә бердәм сәясәтне гамәлгә ашыру;

5.1.12. торак фонды, коммуналь инфраструктура объектлары белән Казан шәһәре муниципаль казнасын формалаштыруны контрольдә тоту;

5.1.13. Казан шәһәре коммуналь инфраструктурасы системасын һәм коммуналь комплекс оешмаларын комплекслы үстерү программасы үтәлешен контрольдә тотуны оештыру;

5.1.14. торак-коммуналь хуҗалыкны карап тоту буенча шәһәр программаларын гамәлгә ашыруга заказ бирүче функцияләрен һәм аларның үтәлеше буенча техник күзәтчелек функцияләрен билгеләнгән тәртип нигезендә башкаруны оештыру;

5.1.15. шәһәр әһәмиятендәге су ресурсларын билгеләнгән тәртиптә файдалануга бирүне килештерү, үз вәкаләтләре кысаларында судан файдалану турында бәхәсләрне хәл итү, су белән тәэмин итү корылмаларының төзелешен һәм кулланылышын контрольдә тотуны оештыру;

5.1.16. халыкны электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итүне, юынтык суларны чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;

5.1.17. коммуналь хуҗалык объектларын тиешенчә эксплуатацияләүне контрольдә тоту, су, газ, җылылык, энергия белән тәэмин итү, юынтык суларны чыгару объектларының, шәһәрнең инженерлык сагы гидротехник корылмаларының тотрыклы эшләвен тәэмин итү;

5.1.18. табигый бәла-казалар һәм аварияләр очрагында үз вәкаләтләре чикләрендә халыкның иминлеген тәэмин итү чараларын күрүне оештыру;

5.1.19. коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәтләренә тарифларны, коммуналь инфраструктура системаларына тоташуга тарифларны, коммуналь комплекс оешмалары товарларына һәм хезмәтләренә тарифларга

өстәмәләр, торак бинаны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләүне законнарда билгеләнгән тәртиптә җайга салу мәсьәләләре буенча Башкарма комитетның хокукый актларын әзерләүне һәм килештерүне оештыру;

5.1.20. муниципаль торак фондын исәпкә алуны оештыру;

5.1.21. муниципаль торак фондыннан файдалану һәм аның сакланышын, әлеге фондка караган торак биналарның билгеләнгән санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, законнарның башка таләпләренә туры килүен контрольдә тоту эшен оештыру;

5.1.22. муниципаль махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннар бирүне оештыру;

5.1.23. муниципаль торак фондының торак урыннарын билгеләнгән тәртиптә – яшәү өчен яраксыз, ә күпфатирлы йортларны авария хәлендә дип тану буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру;

5.1.24. шәһәр территориясендә урнашкан зиратларны (җәмәгать зиратларын һәм башкаларны) эксплуатацияләүне, гражданнарның җирләү урыннарына иркле керә алуын тәэмин итә торган итеп территорияне планлаштыру эшен оештыру, башка җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тотуны тәэмин итү;

5.1.25. шәһәр чикләрендә җирләү урыннарын булдыру турында карар кабул итү;

5.1.26. коррупциягә каршы көрәш чараларын оештыру;

5.1.27. муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын үтәү, Башкарма комитетның әлеге нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән структур бүлекчәләре үз вәкаләтләрен башкарганда эшне оештыру өлешендә эшчәнлекне контрольдә тоту һәм координацияләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

5.1.28. торак урыннар хуҗалары гамәлдәге законнар нигезендә идарә итү ысулын сайламаган яки барлык торак урыннар муниципаль милектә булган күпфатирлы йортлар белән идарә итү өчен идарәче оешмаларны сайлап алу буенча ачык конкурслар оештыру;

5.1.29. Башкарма комитетның торак фондын муниципаль милек составына тапшыру турында хокукый акт проектларын әзерләүне оештыру;

5.1.30. оештыру-хокукый төрләренә бәйсез рәвештә идарәче оешмалар эшчәнлеге өчен тигез шартлар тәэмин итү;

5.1.31. гражданнар оборонасы, халыкны һәм шәһәр территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау планнарын гамәлгә ашыруны оештыру;

5.1.32. торак-коммуналь хуҗалык объектларында төзекләндерү, чисталыкны һәм тәртипне тәэмин итү кагыйдәләрен үтәүне үз вәкаләтләре чикләрендә контрольдә тотуны оештыру;

5.1.33. аз керемле затларга муниципаль торак фондының торак урыннарын социаль наем шартнамәләре буенча бирүне оештыру;

5.1.34. Социаль ипотека программасы һәм башка муниципаль торак программалары кысаларында торак шартларын яхшыртырга теләгән гражданнарны исәпкә алу, исәптән төшерү, исәп эшләрен формалаштыруны оештыру;

5.1.35. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлдә булган торак программаларын гамәлгә ашыру буенча чаралар оештыру;

5.1.36. торак фондына караган милектә урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр куюны тәэмин итү;

5.1.37. инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру;

5.1.38. Башкарма комитет тарафыннан үткәрелә торган мобилизация әзерлеге чараларында катнашу;

5.1.39. шәһәрнең энергетика һәм торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә мобилизация әзерлеген оештыру һәм тәэмин итү;

5.1.40. Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының шәһәр читендә урнашкан идарә пунктларын эшкә әзер тоту буенча чаралар оештыру һәм аларны тәэмин итү;

5.1.41. шәһәр эвакуация комиссиясе эшчәнлеген оештыру һәм тәэмин итү;

5.1.42. гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү чараларын оештыру;

5.1.43. Казан шәһәре территориясендә өлешкә кереп төзү өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек чараларын оештыру;

5.1.44. 2005 елның 1 гыйнварына кадәр торак урыннарына мохтаҗлар исәбенә кабул ителгән гражданнарның түбәндәге категорияләре исәбен алып бару һәм аларга торак бирү чараларын оештыру:

- хәрби хезмәт инвалидлары;
- сугыш хәрәкәтләре ветераннары;
- һәлак булган (үлгән) хәрби хезмәт инвалидларының, сугыш хәрәкәтләре ветераннарының гаиләләре;
- Чернобыль атом электр станциясендәге һәлакәт инвалидлары һәм аларга тиңләштерелгән затлар;
- Ерак Төньяк районнарыннан 1992 елның 1 гыйнварыннан соң кайткан гражданнар;

- хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнар;

5.1.45. муниципаль торак контролен оештыру;

5.1.46. террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу;

5.1.47. террорчылык күренешләре нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү эшендә катнашу;

5.1.48. яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда ярдәм итү программасын эшләү һәм гамәлгә ашыру эшчәнлеген оештыру;

5.1.49. халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау өчен кирәкле көч һәм чараларны әзерләүне һәм аларны әзерлектә тотуны, халыкны мондый хәлләрдә сакланырга һәм эш итәргә өйрәтүне оештыру;

5.1.50. халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат җыюны һәм әлеге мәгълүмат белән алышуны, халыкка гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы туу яки килеп чыгу турында вакытында хәбәр итүне һәм мәгълүмат бирүне тәэмин итүне оештыру;

5.1.51. авария-коткару эшләрен һәм башка кичектергесез эшләр уздыруны, аларны үткәргәндә җәмәгать тәртибен саклауны оештыру;

5.1.52. террорчылык күренешләре нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү эшләрен оештыру;

5.1.53. шәһәр чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итүне оештыру;

5.1.54. күрсәтмә агитация урнаштыруны да кертеп, шәһәрдә янгын профилактикасын оештыру;

5.1.55. шәһәр халкын һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә белемнәрне пропагандалауны оештыру, халыкны һәм оешмалар хезмәткәрләрен гадәттән тыш хәлләр шартларында эш итүгә әзерләүдә катнашу;

5.1.56. гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен матди ресурсларның номенклатур составын һәм резервлар күләмен булдыруны, урнаштыруны, билгеләүне оештыру;

5.1.57. куркыныч янау турында хәбәр итү системаларының даими әзерлеген тәэмин итүне оештыру;

5.1.58. хезмәт күрсәтелә торган объектларда һәм шәһәр территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтүне һәм бетерүне, башка объектларда һәм территорияләрдә гадәттән тыш хәлләрне бетергәндә көчләрнең һәм чараларның үзара хезмәттәшлеген оештыру;

5.1.59. авария-коткару хезмәтләре һәм формированиеләре идарә органнарына, көчләренә һәм чараларына гадәттән тыш хәлләр зонасына чыгуда һәм гадәттән тыш хәлләрне бетерү эшләрен үткәрүгә даими әзер торуда ярдәм итүне оештыру;

5.1.60. хезмәт күрсәтелә торган объектларның һәм территорияләрнең аларда гадәттән тыш хәлләрне бетерү эшләрен башкаруга әзерлеген контрольдә тотуны оештыру;

5.1.61. суда коткару хезмәтен төзүне һәм аның эше белән җитәкчелек итүне оештыру;

5.1.62. дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматларның яшеренлек һәм аларны саклау режимы таләпләрен үтәүне тәэмин итү;

5.1.63. дәүләт серенә рөхсәт бирү турында карар кабул иткән җитәкче белән чит илгә чыгуны билгеләнгән тәртиптә килештерү;

5.1.64. кул астында эшләүче хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт серен саклау турындагы законнарның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;

5.1.65. Башкарма комитетның ведомство карамагындагы бүлекчә хезмәткәрләре белән производствода бәхетсезлек очрагы килеп чыккан вакыттан алып бер тәүлек эчендә гамәлдәге законнар һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән органнарга бу хакта хәбәр итүне тәэмин итү;

5.1.66. каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә экологик тәрбия бирүне оештыруда һәм экологик культура формалаштыруда катнашу;

5.1.67. каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) урнаштыру схемасын билгеләүдә катнашу һәм каты коммуналь калдыклар туплау урыннары (мәйданчыклары) реестрын алып бару.

5.1.68. Казан шәһәре җирле үзидарә органнарында хәбәр итүнең техник чараларын куллануга даими әзерлектә торуны контрольдә тотуны тәэмин итү;

5.1.69. торак урыннарны хосусыйлаштыру процессын законнар нигезендә оештыру, торак урыннарны гражданнар милкенә түләүсез тапшыру турында килешүләр төзү.

5.2. Башкарма комитет Җитәкчесенең торак-коммуналь хуҗалык һәм гражданнарны яклау мәсьәләләре буенча урынбасары үз вәкаләтләре чикләрендә:

а) түбәндәгеләрнең эшен координацияли:

- Башкарма комитетның Торак-коммуналь хуҗалык комитеты;
- Башкарма комитетның Ритуаль хезмәтләрне оештыру идарәсе;
- Башкарма комитетның Торак сәясәте идарәсе;
- Башкарма комитетның Гражданнарны яклау идарәсе;

б) түбәндәгеләрнең эшен контрольдә тота һәм эшчәнлекләренең нәтиҗәлелек күрсәткечләре үтәлеше өчен җавап бирә:

- Казан шәһәренең «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе;

- «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте;

- «Ритуал» акционерлык җәмгыяте;

- «Торак-коммуналь хуҗалыкны карап тоту һәм тышкы төзекләндерү буенча шәһәр программаларын гамәлгә ашыруга техник күзәтчелек хезмәте» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

- Казан шәһәренең берләштерелгән дежур-диспетчерлык хезмәте;

- үз вәкаләтләре чикләрендә башка муниципаль унитар предприятиеләр һәм учреждениеләр;

в) үз карамагындагы предприятиеләрнең җитәкчеләрен вазифага билгеләү, алар белән хезмәт килешүләре төзү, үзгәртү, гамәлдән чыгару, аларга карата дисциплинар җәза куллану турында тәкъдимнәр кертә;

г) үз карамагындагы учреждение җитәкчеләренең чираттагы ялларын һәм командировкаларын килештерә;

д) түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

- «Казан җылылык челтәре компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте;

- «Казаньгоргаз» эксплуатацияләү-җитештерү идарәсе;

- Казан электр челтәрләре – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте филиалы;–

- «Таттеплосбыт» ачык акционерлык җәмгыяте;

- Казан шәһәре торак инспекциясе;

- Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе;

- Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре идарәсе;

- күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеге алып бара торган оешмалар;

- әлеге нигезләмәнең 5.2 пунктында күрсәтелгән структур бүлекчәләрнең вәкаләтләре өлкәсендә муниципаль контрактларны (башка килешүләрне) үтәү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган оешмалар;

е) Башкарма комитет Җитәкчесе йөкләмәсе нигезендә үз эшчәнлеге юнәлеше буенча комиссияләргә җитәкчелек итә, штабларны, эшче төркемнәрне җитәкли, үз вәкаләтләре кысаларында Башкарма комитет Җитәкчесенең башка йөкләмәләрен үти.

5.3. Башкарма комитет Җитәкчесенең торак-коммуналь хуҗалык һәм гражданнарны яклау мәсьәләләре буенча урынбасары үз вәкаләтләрен башкару максатыннан боерыклар чыгара, шулай ук башка документларны имзалый.

## VI. Башкарма комитет Җитәкчесенең төзекләндерү мәсьәләләре буенча урынбасары вәкаләтләре

6.1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүне һәм Башкарма комитет эшчәнлеген оештыру максатыннан Башкарма комитет Җитәкчесенең төзекләндерү мәсьәләләре буенча урынбасарына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

6.1.1. Казан шәһәре территориясендә төзекләндерү объектларын карап тоту һәм үстерү өлкәсендәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

6.1.2. заказ бирүче функциясен гамәлгә ашыру һәм җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларына (юл эшчәнлеге) карата төзелеш, капиталь ремонт, проектлау, реконструкцияләү программаларын һәм Казан шәһәренең төзекләндерү программаларын гамәлгә ашыру буенча заказ бирүче функциясен үтәүне контрольдә тотуны, шулай ук башкарыла торган эшләрнең проект документларына, техник регламент таләпләренә, инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә, җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планы таләпләренә туры килү-килмәвен контрольдә тотуны тәэмин итү;

6.1.3. үз вәкаләтләре чикләрендә шәһәр халкының санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү;

6.1.4. шәһәр территориясендә гигиена чараларын һәм санитар-эпидемиологик чаралар үткәрүне оештыру, шулай ук үз вәкаләтләре чикләрендә санитар кагыйдәләрне, нормаларны һәм гигиена нормативларын үтәүне тәэмин итү;

6.1.5. шәһәрне төзекләндерүне оештыру, килешү нигезендә, әлеге эшкә эшмәкәрләрне, предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны, шулай ук халыкны җәлеп итү;

6.1.6. шәһәр өчен социаль әһәмияткә ия булган эшне (шул исәптән кизү торуны) ирекле рәвештә оештыру;

6.1.7. үз вәкаләтләре чикләрендә шәһәр территориясендә әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын үткәрүне оештыру;

6.1.8. шәһәр территориясендә рөхсәтсез булдырылган чүплекләрне бетерү эшләрен башкаруны контрольдә тотуны оештыру;

6.1.9. халыкның экологик яктан белемнәрен арттыруны, шул исәптән халыкка әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар һәм экологик куркынычсызлык өлкәсендәге законнар турында мәгълүмат бирүне гамәлгә ашыруны оештыру;

6.1.10. җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын һәм төзекләндерү объектларын яктырту эшен оештыру;

6.1.11. җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын үстерү өлкәсендә инвестиция сәясәтенең төп юнәлешләрен эшләүне гамәлгә ашыру;

6.1.12. җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының сакланышын оештыру һәм тәэмин итү;

6.1.13. җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан түләүле нигездә файдалануга һәм бу рәвешле файдалануны туктату турында карарлар итүгә кагылышлы тәкъдимнәр әзерләүне оештыру;

6.1.14. җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы түләүле автомобиль юлларында транспорт чаралары йөргән өчен түләүне исәпләү методикасын һәм аның максималь күләмен билгеләүне оештыру;

6.1.15. җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген, җирле әһәмияткә ия гомуми файдалануда булмаган автомобиль юллары исемлеген раслау турында муниципаль хокукый акт проектын билгеләнгән тәртиптә эшләү һәм раслауга кертү;

6.1.16. җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап хәрәкәт иткәндә авыр йөк ташый торган транспорт чаралары тарафыннан китерелгән зыян күләмен исәпләү эшен оештыру;

6.1.17. җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыруны контрольдә тоту;

6.1.18. Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә куркыныч, авыр йөк һәм (яки) зур габаритлы йөкләр ташый торган транспорт чарасы маршрутын килештерүне, аңа автомобиль юллары буйлап хәрәкәт итүгә махсус рөхсәт бирүне оештыру;

6.1.19. юл сервисы объектларын җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына тоташтыру хезмәтләре бәясен һәм исемлеген ачыклау турында муниципаль хокукый акт проектын билгеләнгән тәртиптә эшләү һәм раслауга кертү;

6.1.20. җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын карап тотуга финанс чыгымнары нормативлары һәм күрсәтелгән максатларга җирле бюджет

ассигнованиеләре күләмен исәпләү кагыйдәләре турында тәкъдимнәр әзерләү эшен оештыру;

6.1.21. җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында күчәр йөкләнеше нормативтан артык булган һәм габаритлы транспорт чаралары хәрәкәтен оештыру турында муниципаль хокукый актлар проектларын билгеләнгән тәртиптә эшләү һәм раслауга кертү;

6.1.22. ясалма юл корылмаларын, җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын карап тотуны оештыру һәм тәэмин итү;

6.1.23. Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итүдә катнашу;

6.1.24. шәһәр муниципаль милкендә булган су объектларын саклау чараларын оештыру;

6.1.25. суның тискәре йогынтысын булдырмау һәм аның нәтиҗәләрен бетерү чараларын оештыру;

6.1.26. шәһәр муниципаль милкендәге су объектларыннан файдаланган өчен түләү ставкасын билгеләү, бу түләүне исәпләү һәм алу тәртибе турында тәкъдимнәр әзерләү буенча эшләрне координацияләү;

6.1.27. шәһәр территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси ихтыяҗлар өчен һәм көнкүрештә файдалану кагыйдәләрен билгеләнгән тәртиптә эшләү һәм раслауга кертү;

6.1.28. гражданнарга шәһәр территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларында судан файдалануны чикләү турында мәгълүмат җиткерү эшләрен оештыру;

6.1.29. ясалма юл корылмаларында мәйданнарны арендалау килешүләре төзүгә хокукларны сату буенча сатулар үткәрүне оештыру;

6.1.30. шәһәр территориясендә яшел үсентеләрне кисү турында карарлар кабул итү;

6.1.31. тиешле акт төзеп, яшел үсентеләрне тикшерү эшләрен оештыру;

6.1.32. яшелләндерүне, яшел үсентеләрне һәм сулыкларны саклауны оештыру, гамәлдәге законнар нигезендә яшел үсентеләрне кисүгә рөхсәтләр бирү;

6.1.33. шәһәр урманнарын, шәһәр эчендә урнашкан махсус саклана торган табигать территорияләре урманнарын рациональ файдалану, саклау, яклау, яңадан торгызу эшләрен оештыру;

6.1.34. шәһәр муниципаль милкендәге урман ресурслары (агач материаллары) күләме бирәмлеге өчен түләү ставкасын һәм, арендага бирү

максатыннан, урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкасын билгеләү турында тәкъдимнәр әзерләү эшен оештыру;

6.1.35. урман хуҗалыгы регламентларын эшләү һәм раслауга кертү;

6.1.36. муниципаль милектә булган урманнарны үзләштерү проектларына муниципаль экспертиза үткәрүне оештыру;

6.1.37. шәһәр муниципаль милкендә булган урман кишәрлекләренә карата муниципаль урман контролен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыруда катнашу;

6.1.38. тиешле административ регламент белән билгеләнә торган муниципаль хокукый актлар таләпләренең Казан шәһәре территориясендә үтәлешенә 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында»гы федераль закон нигезендә муниципаль контроль оештыру һәм аны гамәлгә ашыру;

6.1.39. төзекләндерү кагыйдәләренең үтәлешен, төзекләндерү объектларында чисталыкның һәм тәртипнең тәэмин ителешен үз вәкаләтләре кысаларында контрольдә тоту;

6.1.40. үз вәкаләтләре кысаларында халыкны кабул итүне оештыру, шулай ук гражданнарның шикаятьләрен, гаризаларын һәм тәкъдимнәрен карап тикшерү, алар буенча кирәкле чаралар күрү;

6.1.41. муниципаль контрактлар төземичә гамәлгә ашырылган сатып алулар реестрын координацияләү һәм алып бару;

6.1.42. агынты сулар (яңгыр сулары) канализациясе объектларыннан тиешенчә файдалануны координацияләү һәм контрольдә тоту;

6.1.43. гомуми файдаланудагы автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полоса чикләрендә биналар, җир асты һәм җир өсте инженер челтәрләрен, корылмаларны, юл өслекләрен, тышкы төзекләндерүне бозуга бәйле башка күчемсез милек объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, ремонтлау вакытында җир эшләрен (шул исәптән авария-торгызу эшләрен) башкаруга рөхсәтләр (ордерлар) теркәүне, рәсмиләштерүне, бирүне һәм озайтуны оештыру;

6.1.44. инженерлык коммуникацияләрен үткәрү, үзгәртеп салу һәм ремонтлау, төзекләндерүне торгызу буенча башкарылган эшләрне координацияләү һәм кабул итүне оештыру;

6.1.45. инженерлык коммуникацияләрендә башкарыла торган авария-торгызу эшләренең бердәм реестрын координацияләү һәм алып бару;

6.1.46. яңгыр һәм кар суларын чыгаруга техник шартлар бирүне оештыру һәм техник шартларның үтәлешен контрольдә тоту;

6.1.47. җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтенә вакытлыча чикләүләр кертүне яки хәрәкәтне туктатуны оештыру;

6.1.48. төзелә яки файдалануга тапшырыла торган капиталь төзелеш объектлары территориясен төзекләндерү эшләрен контрольдә тоту вәкаләтләрен, тиешле белешмәләр төзеп, проект документлары нигезендә гамәлгә ашыру;

6.1.49. Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юллары турында белешмәләр әзерләү һәм тапшыру;

6.1.50. коррупциягә каршы көрәш чараларын оештыру;

6.1.51. муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын үтәү, әлеге нигезләмәнең 6.2 пунктында күрсәтелгән Башкарма комитетның структур бүлекчәләре үз вәкаләтләрен башкарганда эшне оештыру өлешендә эшчәнлекне контрольдә тоту һәм координацияләү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;

6.1.52. инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру;

6.1.53. Башкарма комитет тарафыннан үткәрелә торган мобилизация әзерлеге чараларында катнашу;

6.1.54. җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларының һәм күперләрнең мобилизация әзерлеген оештыру, оборона максатыннан аларның техник ябылуын планлаштыру;

6.1.55. төзү, ремонтлау, реконструкцияләү (реставрацияләү) эшләре тәмамланганнан соң файдалануга тапшырыла торган җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын эксплуатацияләүче оешмаларга законнар белән билгеләнгән тәртиптә тапшыруны оештыру;

6.1.56. бюджет сметасы буенча сатып алынган милектән тыш, оператив идарәдә булган муниципаль күчемсез милекне арендалау килешүләрен, шул исәптән аренда килешүләрен төзүгә хокукларны сатканда төзелә торган килешүләрне төзүне оештыру, аренда түләве керүнең исәбен алып бару;

6.1.57. муниципаль казнадагы ясалма юл корылмаларын, урамнарны, мәйданнарны, паркларны, скверларны, бульварларны, ишегалларын һәм җәяүле юлларын яктырту өчен билгеләнгән тышкы яктырту системаларын, шулай ук территорияләрне төзекләндерү элементларын (тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларыннан тыш) объектлата исәпкә алуны алып бару;

6.1.58. террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу;

6.1.59. террорчылык күренешләре нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү эшендә катнашу;

6.1.60. дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматларның яшеренлек һәм аларны саклау режимы таләпләрен үтәүне тәэмин итү;

6.1.61. дәүләт серенә рөхсәт бирү турында карар кабул иткән җитәкче белән чит илгә чыгуны билгеләнгән тәртиптә килештерү;

6.1.62. кул астында эшләүче хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт серен саклау турындагы законнарның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;

6.1.63. Башкарма комитетның ведомство карамагындагы бүлекчә хезмәткәрләре белән производствода бәхетсезлек очрагы килеп чыккан вакыттан алып бер тәүлек эчендә гамәлдәге законнар һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән органнарга бу хакта хәбәр итүне тәэмин итү;

6.1.64. Казан шәһәре Башкарма комитетеның 2018 елның 11 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җирләрне рекультивацияләү мәсьәләләре буенча даими комиссия белән җитәкчелек итү;

6.2. Башкарма комитет Җитәкчесенең төзекләндерү мәсьәләләре буенча урынбасары:

а) Башкарма комитетның Тышкы төзекләндерү комитеты эшен координацияли;

б) түбәндәгеләрнең эшен контрольдә тота һәм эшчәнлекләренең нәтиҗәлелек күрсәткечләре үтәлеше өчен җавап бирә:

- «Киров районының юл ремонт-эксплуатация идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе;

- «Горводзеленхоз» су һәм яшел хуҗалык шәһәр җитештерү тресты муниципаль унитар предприятиесе;

- Казан шәһәренең «Шәһәр күперләре» муниципаль унитар предприятиесе;

- Казан шәһәренең «Шәһәрне төзекләндерү» муниципаль унитар предприятиесе;

в) үз карамагындагы предприятиеләрнең җитәкчеләрен вазифага билгеләү, алар белән хезмәт килешүләре төзү, үзгәртү, гамәлдән чыгару, аларга карата дисциплинар җәза куллану турында тәкъдимнәр кертә;

г) әлеге нигезләмәнең 6.2 пунктында күрсәтелгән структур бүлекчәләрнең вәкаләтләре өлкәсендә муниципаль контрактларны (башка килешүләрне) үтәү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар белән хезмәттәшлек итә;

д) Башкарма комитет Җитәкчесе йөкләмәсе нигезендә үз эшчәнлеге юнәлеше буенча комиссияләргә җитәкчелек итә, штабларны, эшче төркемнәрне

җитәкли, үз вәкаләтләре кысаларында Башкарма комитет Җитәкчесенең башка йөкләмәләрен үти.

6.3. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Башкарма комитет Җитәкчесенең төзекләндерү мәсьәләләре буенча урынбасары үз вәкаләтләре кысаларында боерыклар чыгара, шулай ук башка документларны имзалый.

## VII. Башкарма комитет Җитәкчесенең транспорт, икътисади үсеш һәм сәүдә мәсьәләләре буенча урынбасары вәкаләтләре

7.1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүне һәм Башкарма комитет эшчәнлеген оештыру максатыннан Башкарма комитет Җитәкчесенең транспорт, икътисади үсеш һәм сәүдә мәсьәләләре буенча урынбасарына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

7.1.1. Казан шәһәренең социаль-икътисади үсеш стратегиясен эшләүне оештыру;

7.1.2. шәһәрнең һәм шәһәр икътисады тармакларының социаль-икътисади үсеше буенча фаразлар эшләүне оештыру;

7.1.3. җинаять-башкару законнары нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнә торган төрләр һәм объектлар буенча Казан шәһәрендә мәҗбүри һәм төзәтү эшләре рәвешендәге җәзаларны үтәү мәсьәләләре буенча җинаять-башкару инспекцияләре белән хезмәттәшлекне оештыру;

7.1.4. Казан шәһәре муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре күрсәтә торган хезмәтләргә, башкара торган эшләргә тарифларны билгеләү җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кергән һәм Казан шәһәре Думасының 2006 елның 20 апрелендәге 9-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль предприятиеләре һәм учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә, башкарыла торган эшләргә тарифлар билгеләү тәртибе белән җайга салынган очракта, әлеге эшне координацияләү;

7.1.5. таможня законнарын үтәү һәм тышкы сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча таможня органнары белән үзара хезмәттәшлекне оештыру;

7.1.6. шәһәрдә инвестиция-инновация сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итүне контрольдә тоту, инвестиция һәм инновация сәясәте программаларын эшләүдә һәм формалаштыруда катнашу;

7.1.7. җирле салымнарны кертү яки гамәлдән чыгару буенча тәкъдимнәр формалаштыру, предприятиеләргә, оешмаларга һәм кече эшмәкәрлек

субъектларына икътисади яктан нигезләнгән салым ташламалары бирү механизмын гамәлгә ашыру;

7.1.8. шәһәр карамагындагы предприятиеләрдә, учреждениеләрдә һәм оешмаларда статистик исәпнең һәм хисапларның торышын контрольдә тотуны оештыру;

7.1.9. хезмәт һәм мәшгульлек өлкәсендә кешеләрне социаль яктан яклауны тәэмин итү эшен координацияләү;

7.1.10. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре идарәсе белән хезмәт миграциясе мәсьәләләре өлкәсендә үзара хезмәттәшлекне оештыру;

7.1.11. Казан шәһәренең социаль-икътисади үсеш стратегиясен гамәлгә ашыруны координацияләү;

7.1.12. Казан шәһәре халкын кабул итүне оештыру, шулай ук гражданнарның шикаятьләрен, гаризаларын һәм тәкъдимнәрен карап тикшерү, алар буенча үз вәкаләтләре кысаларында кирәкле чаралар күрү;

7.1.13. халыкара финанс институтлары белән инвестицияләр җәлеп итү эшен оештыру;

7.1.14. коррупциягә каршы көрәш чараларын оештыру;

7.1.15. Башкарма комитет тарафыннан үткәрелә торган мобилизация әзерлеге чараларында катнашу;

7.1.16. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге икътисадының мобилизация планын эшләүне, төгәлләштерүне һәм гамәлгә кертүгә әзерлекне оештыру;

7.1.17. сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү өлкәсендә бердәм сәясәтне гамәлгә ашыру эшен координацияләү;

7.1.18. кулланучылар базары торышын мониторинглауны контрольдә тоту;

7.1.19. халыкның сәүдә мәйданнары белән тәэмин ителеше нормативларын исәпкә алып, стационар булмаган сәүдә объектларын, шул исәптән сезонлы объектларны урнаштыру схемасын төзү эшләрен координацияләү;

7.1.20. Казан шәһәре территориясендә законсыз урнаштырылган сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү объектларын сүтү һәм саклау эшләрен оештыру;

7.1.21. шәһәрнең транспорт хезмәте күрсәтү системасын үстерүне координацияләүне һәм планлаштыруны оештыру, муниципаль транспорт предприятиеләренең тиешенчә эшләве өчен шартлар тудыруны тәэмин итү, аларның эшен контрольдә тоту;

7.1.22. шәһәр җәмәгать транспортында пассажирлар йөртүне оештыру һәм үз вәкаләтләре кысаларында пассажирларга хезмәт күрсәтү сыйфатын контрольдә тоту;

7.1.23. шәһәр территориясендәге җәмәгать транспорты тукталышлары исемлеген раслау һәм аларны күрсәткечләр белән тәэмин итү;

7.1.24. маршрутларны, транспорт хәрәкәте графигын раслау, пассажирлар йөртү өлкәсендә эшмәкәрлек эшчәнлеге алып баручы затларны билгеләнгән тәртиптә килешү нигезендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүгә җәлеп итү;

7.1.25. шәһәрдә пассажирлар йөртү буенча диспетчерлык идарәсен оештыру һәм пассажир транспорты эшен линияле контрольдә тотуны оештыру;

7.1.26. пассажирлар йөртүгә муниципаль заказ урнаштыруны оештыру;

7.1.27. вокзал, пристань һәм аэропортларда пассажирларга куркынычсыз хезмәт күрсәтүне контрольдә тотуны оештыру;

7.1.28. Казан шәһәрендә транспорт сәясәте һәм юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә чараларны тәэмин итү эшен координацияләү;

7.1.29. автомобиль транспортының туктап тору һәм парковка урыннарын тәртипкә салу, әлеге объектларны урнаштыру өчен бирелә торган шәһәр җирләреннән рациональ һәм максатчан файдалану эшен координацияләү;

7.1.30. юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү эшен оештыру;

7.1.31. юл хәрәкәтен оештыруның техник чаралары эшен оештыру, юл хәрәкәтен оештыруда техник чараларны урнаштыруның техник шартларын, урыннарын килештерү, урам-юл челтәрен үстергәндә башка стандартларны һәм кагыйдәләрне үтәүне тәэмин итү;

7.1.32. җирле әһәмияткә ия гомуми файдаланудагы автомобиль юлларыннан файдаланучыларны мәгълүмат белән тәэмин итүне оештыру;

7.1.33. Казан шәһәренең автомобиль юллары участокларында юл билгеләре урнаштыру схемаларын раслау;

7.1.34. Казан шәһәре территориясендә урнашкан яки эшчәнлек алып баручы физик һәм юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең төзекләндерү өлкәсендә, төзекләндерү объектларында инженерлык-коммуникация (җир) эшләрен, ремонт һәм башка эшләрне башкару, яшел үсентеләр утырту, аларны карап тоту һәм саклау өлкәсендә норматив хокукый актларны үтәү өлешендәге эшчәнлекләренә үз вәкаләтләре чикләрендә контрольлек итүне координацияләү;

7.1.35. 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында»гы федераль

закон таләпләре нигезендә физик һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләре буенча үз вәкаләтләре кысаларында тикшерүләр үткәрүне координацияләү;

7.1.36. террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу;

7.1.37. террорчылык күренешләре нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү эшендә катнашу;

7.1.38. дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматларның яшеренлек һәм аларны саклау режимы таләпләрен үтәүне тәэмин итү;

7.1.39. дәүләт серенә рөхсәт бирү турында карар кабул иткән җитәкче белән чит илгә чыгуны билгеләнгән тәртиптә килештерү;

7.1.40. кул астында эшләүче хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт серен саклау турындагы законнарның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;

7.1.41. Башкарма комитетның ведомство карамагындагы бүлекчә хезмәткәрләре белән производствода бәхетсезлек очрагы килеп чыккан вакыттан алып бер тәүлек эчендә гамәлдәге законнар һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән органнарга бу хакта хәбәр итүне тәэмин итү;

7.1.42. тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсендә бердәм шәһәр сәясәтен гамәлгә ашыру эшләрен координацияләүне тәэмин итү;

7.1.43. җир кишәрлекләрендә, аларның милек төренә бәйсез рәвештә, шулай ук биналарда, корылмаларда яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендә яисә шәһәрнең муниципаль милкендә булган башка күчемсез милектә реклама корылмаларын урнаштыру схемасын эшләүне оештыру;

7.1.44. шәһәрдә урнаштырыла торган тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларының югары сыйфат стандартларын тәэмин итү;

7.1.45. Казан шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру хокукына сатулар үткәрүне контрольдә тоту;

7.1.46. реклама корылмаларын урнаштыруга һәм алардан файдалануга рөхсәтләр бирүне (рөхсәт бирүне кире кагу) һәм аларны гамәлдән чыгаруны, тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыруга 2014 елның 1 гыйнварына кадәр бирелгән килештерүләрне кире алуны оештыру;

7.1.47. Казан шәһәренең муниципаль милек объектларында рөхсәтсез урнаштырылган реклама корылмаларын сүтү турында күрсәтмәләр, законсыз урнаштырыла торган тышкы мәгълүмат чараларын сүтү турында таләпләр бирүне оештыру;

7.1.48. Казан шәһәре территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын инвентаризацияләүне гамәлгә ашыруны контрольдә тоту;

7.1.49. тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларының шәһәр реестрын алып баруны оештыру;

7.1.50. шәһәр мәгълүматын, социаль реклама һәм мобилизация турында дәүләт органнары мәгълүматын урнаштыру буенча эшләр оештыру;

7.1.51. Казан шәһәре территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыруга карата таләпләрнең үтәлешен контрольдә тоту;

7.1.52. тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннарын һәм тышкы күренешләрен килештерүне оештыру;

7.2. Башкарма комитет Җитәкчесенең транспорт, икътисади үсеш һәм сәүдә мәсьәләләре буенча урынбасары үз вәкаләтләре чикләрендә:

а) түбәндәгеләрнең эшен координацияли:

- Башкарма комитетның Кулланучылар базары комитеты;

- Башкарма комитетның Транспорт комитеты;

- Башкарма комитетның Административ-техник инспекция идарәсе;

- Башкарма комитетның Тышкы реклама һәм мәгълүмат идарәсе;

- Башкарма комитет Аппаратының икътисади үсеш комитеты;

- Башкарма комитет Аппаратының административ комиссияләр эшчәнлеген оештыру идарәсе;

б) түбәндәгеләрнең эшен контрольдә тота һәм эшчәнлекләренең нәтиҗәлелек күрсәткечләре үтәлеше өчен җавап бирә:

- «Казан шәһәренең азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» акционерлык җәмгыяте;

- «Казан ярминкәсе» ачык акционерлык җәмгыяте;

- «Мәскәү базары» ачык акционерлык җәмгыяте;

- «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе;

- Казан шәһәренең «2 номерлы пассажир автотранспорты предприятиесе» муниципаль унитар предприятиесе;

- «Пассажирлар йөртүне оештыручы» муниципаль казна учреждениесе;

- Казан шәһәренең «Юл хәрәкәте белән идарә итүнең автоматлаштырылган системасы» муниципаль казна учреждениесе;

- «Шәһәр парковка киңлеген оештыручы» муниципаль казна учреждениесе;

- «Казан шәһәренең дезинфекция станциясе» муниципаль бюджет учреждениесе;

- «Транспорт картасы» акционерлык җәмгыяте;

в) үз карамагындагы предприятиеләрнең җитәкчеләрен вазифага билгеләү, алар белән хезмәт килешүләре төзү, үзгәртү, гамәлдән чыгару, аларга карата дисциплинар җәза куллану турында тәкъдимнәр кертә;

г) үз карамагындагы муниципаль учреждениеләр җитәкчеләрен вазифага билгели һәм вазифадан азат итә, аларга карата дисциплинар җәза чараларын куллана, аларның чираттагы ялларын һәм командировкаларын килештерә;

д) ведомство карамагындагы учреждение җитәкчеләренең чираттагы ялларын һәм командировкаларын килештерә;

е) түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

- әлеге нигезләмәнең 7.2 пунктында күрсәтелгән структур бүлекчәләрнең вәкаләтләре өлкәсендә муниципаль контрактларны (башка килешүләрне) үтәү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган оешмалар;

- Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең эпидемиологик күзәтчелек бүлеге;

- «Казан Банкы» икътисади үсеш коммерция банкы җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте;

- «Тасма: Активлар һәм Идарә» ачык акционерлык җәмгыяте;

- Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

- Татарстан таможнясы;

- Татарстан Республикасы буенча дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең территориаль органы;

- Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре идарәсе (хезмәт миграциясе мәсьәләләре буенча);

- Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

- Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекциясе идарәсе (хәрәкәтне оештыруның техник чараларын гамәлгә кертү, урам-юл челтәрен үстерү, транспорт сәясәте һәм юл хәрәкәте иминлеген мәсьәләләрендә);

- Идел-Нократ транспортта эчке эшләр идарәсенең Казан транспортта эчке эшләр идарәсе линиясе;

- Россия Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

- «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе;

ж) Башкарма комитет Җитәкчесе йөкләмәсе нигезендә үз эшчәнлеге юнәлеше буенча комиссияләргә җитәкчелек итә, штабларны, эшче төркемнәрне

җитәкли, үз вәкаләтләре кысаларында Башкарма комитет Җитәкчесенең башка йөкләмәләрен үти.

7.3. Үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатыннан Башкарма комитет Җитәкчесенең транспорт, икътисади үсеш һәм сәүдә мәсьәләләре буенча урынбасары боерыклар чыгара, шулай ук башка документларны имзалый.

## VIII. Башкарма комитет Аппараты җитәкчесенең вәкаләтләре

8.1. Җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүне һәм Башкарма комитет эшчәнлеген оештыру максатыннан Башкарма комитет Аппараты җитәкчесенә түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

8.1.1. Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан Устав белән билгеләнгән җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүне һәм тиешле федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

8.1.2. Башкарма комитет Аппараты, аның структур бүлекчәләре эшчәнлеген хокукый яктан тәэмин итүне оештыру, муниципаль хокукый актларга база булдыру, аны алып бару һәм хокукый экспертиза ясау;

8.1.3. Башкарма комитет эшен планлаштыруны оештыру, планнарның үтәлешен контрольдә тоту;

8.1.4. Башкарма комитет эшчәнлеген тәэмин итү өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль заказ урнаштыру өчен конкурслар үткәрүне оештыру;

8.1.5. җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүдә Башкарма комитет комитетлары, идарәләре, бүлекләре, муниципаль предприятиеләр һәм оешмаларның үзара хезмәттәшлеген координацияләү;

8.1.6. Башкарма комитет Җитәкчесе, аның урынбасарлары өчен шәһәр хуҗалыгында һәм социаль өлкәдәге эшләр торышы турында аналитик белешмә мәгълүмат, шәһәр хуҗалыгы, социаль инфраструктура белән идарә итү мәсьәләләре буенча, Башкарма комитет органнары һәм район администрацияләре эшчәнлеге турында документлар һәм материаллар әзерләүне оештыру;

8.1.7. Башкарма комитетның хокукый актлары проектларын, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарларының боерыкларын әзерләүне оештыру һәм әлеге проектларны аларга карап тикшерүгә тапшыру;

8.1.8. Башкарма комитет Җитәкчесе адресына депутат тәкъдимнәрен, үтенечләрен, гражданнардан кергән тәкъдимнәрне, үтенечләрне, хатларны һәм

шикаятьләрне карап тикшерүне, өйрәнүне, гомумиләштерүне оештыру, аларны карап тикшерү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

8.1.9. шәһәр территориясендә комитетлар, идарәләр, район администрацияләре, шулай ук юридик һәм физик затлар тарафыннан Башкарма комитет Җитәкчесе карарларын (боерыкларын) һәм йөкләмәләрен, аның урынбасарлары һәм Башкарма комитет Аппараты җитәкчесе боерыкларын үтәүне контрольдә тоту;

8.1.10. бүләкләү, мактаулы исемнәр бирү мәсьәләләре буенча билгеләнгән тәртиптә материаллар әзерләүне оештыру;

8.1.11. Башкарма комитет эше турында аналитик, белешмә һәм документаль материаллар әзерләүне оештыру;

8.1.12. Башкарма комитет Җитәкчесе катнашындагы чараларны мәгълүмати яктан тәэмин итүне оештыру;

8.1.13. Башкарма комитетның тармак һәм территориаль органнарында эш башкаруның бердәм системасын тәэмин итү, кабул ителгән муниципаль хокукый актларны башкаручыларга үз вакытында җиткерү, документлар белән эшләү формаларын һәм алымнарын камилләштерү;

8.1.14. Башкарма комитетның һәм Башкарма комитет Аппаратының финанс-хуҗалык эшчәнлегенең бухгалтерлык исәбен алып баруны оештыру, матди байлыкларның сакланышын, акчаларның дөрес тотылышын контрольдә тоту;

8.1.15. Башкарма комитетта һәм аның структур бүлекчәләрендә кадрлар эше, кадрлар әзерләү һәм яңадан әзерләү, муниципаль хезмәт вазифаларын үтәүгә кандидатларны квалификация буенча сайлап алуны оештыру;

8.1.16. архив эшен оештыру;

8.1.17. Башкарма комитет биналарын, җиһазларын, транспортын, исәпләү техникасы һәм элемтә чараларын тиешенчә карап тотуны тәэмин итүне, аларның техник торышын контрольдә тотуны оештыру;

8.1.18. җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре, пикетлар оештыручыларга ярдәм күрсәтү максатыннан гамәлдәге законнар нигезендә вәкаләтле вәкил билгеләү;

8.1.19. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сайлаулар һәм референдумнар уздыру чорында Казан шәһәре Вахитов районы территориаль сайлау комиссиясенә аның вәкаләтләрен башкаруда ярдәм күрсәтү эшен оештыру;

8.1.20. гомуми юрисдикция судлары эшчәнлеген тәэмин итү өчен присяжный утырышчылар исемлеген төзүне оештыру;

8.1.21. Башкарма комитет Аппараты хезмәткәрләрен вазифага билгеләү һәм азат итү;

8.1.22. үз вәкаләтләре кысаларында халыкны кабул итүне оештыру, шулай ук гражданнарның шикаятьләрен, гаризаларын һәм тәкъдимнәрен карап тикшерү, алар буенча кирәкле чаралар күрү;

8.1.23. Башкарма комитет исеменнән 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында»гы федераль законда каралган барлык вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

8.1.24. коррупциягә каршы көрәш чараларын оештыру;

8.1.25. Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан үткәрелә торган мобилизация әзерлеге чараларында катнашу;

8.1.26. хәрби вакытка Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының оештыру-штат структурасын әзерләүне оештыру;

8.1.27. мобилизация чорына һәм хәрби вакытка Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә запаста торучы гражданнарны Казан шәһәре җирле үзидарә органнарында хәрби исәпкә алуны һәм броньлауны оештыру;

8.1.28. Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең гражданнарны мобилизацияләү комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итүне оештыру;

8.1.29. Башкарма комитетның Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, территориаль органнар һәм оешмалар белән оборона һәм мобилизация өлкәсендә үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү;

8.1.30. Казан шәһәре территориясендә конфессияара татулыкны ныгытуга юнәлдерелгән чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыруны оештыру;

8.1.31. Башкарма комитетта мобилизация әзерлеген методик яктан тәэмин итүне оештыру;

8.1.32. үз карамагындагы учреждениеләр структурасын килештерүдә катнашу;

8.1.33. үз карамагындагы бүлекчәләрнең штат расписаниесен килештерүдә катнашу;

8.1.34. үз җаваплылыгындагы учреждениеләр өчен муниципаль йөкләмә формалаштыруда һәм раслауда катнашу;

8.1.35. тышкы элемтәләрне һәм туризмны үстерү эшчәнлеген оештыру;

8.1.36. шәһәр халкының һәм кунакларының массакүләм ял итүе өчен шартлар тудыру, шәһәр территориясендә туризмны үстерү программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыруны оештыру;

8.1.37. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы федераль закон нигезендә эчке муниципаль финанс контроле эшен оештыру;

8.1.38. Казан шәһәре территориясендә җәмәгать тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итүдә эчке эшләр органнары эшчәнлегенә ярдәм күрсәтү;

8.1.39. җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга, аларның берләшмәләренә ярдәм итү, халык дружиналары һәм тәртип саклау буенча җәмәгать пунктлары эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен шартлар булдыру;

8.1.40. террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалауда катнашу;

8.1.41. террорчылык күренешләре нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү эшендә катнашу;

8.1.42. дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматларның яшеренлек һәм аларны саклау режимы таләпләрен үтәүне тәэмин итү;

8.1.43. дәүләт серенә рөхсәт бирү турында карар кабул иткән җитәкче белән чит илгә чыгуны билгеләнгән тәртиптә килештерү;

8.1.44. кул астында эшләүче хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт серен саклау турындагы законнарның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;

8.1.45. заказ бирүчеләрнең (муниципаль бюджет учреждениеләренең), муниципаль заказ бирүчеләрнең (муниципаль органнарның яки муниципаль казна учреждениеләренең) һәм Казан шәһәренең муниципаль автоном учреждениеләренең сатып алуларын гамәлгә ашыруны оештыру, шулай ук юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алынганда товар белән тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү буенча аерым функцияләр башкару;

8.1.46. Башкарма комитет Аппараты карамагындагы бүлекчә хезмәткәрләре белән производствода бәхетсезлек очрагы килеп чыккан вакыттан алып бер тәүлек эчендә гамәлдәге законнар һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән органнарга бу хакта хәбәр итүне тәэмин итү.

8.1.47. Башкарма комитетта мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итү һәм үстерү эшен оештыру;

8.1.48. цифрлы үсеш, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация инфраструктурасында цифрлы үсеш мәсьәләләрен координацияләү;

8.1.49. цифрлы һәм мәгълүмати технологияләрдән файдалану буенча учреждениеләр эшчәнлеген координацияләү;

8.1.50. Казан шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеге процессларын цифрлаштыру һәм муниципаль идарәне оптимальләштерү буенча проект эшчәнлеген координацияләү;

8.1.51. Казан шәһәрен мәгълүматлаштыру һәм элемтә мәсьәләләре буенча программалар кабул итүдә һәм эш планнарын төзүдә, шәһәр заказы буенча китерелә торган продукциянең тиешле реестрларын төзүдә катнашу, аларны раслауга билгеләнгән тәртиптә тапшыру һәм үтәү буенча комплекслы эшләр башкару; Башкарма комитетның мәгълүмат системаларына һәм ресурсларга, элемтә чараларына, алар белән тәэмин ителешкә булган ихтыяҗы, шулай ук аларны карап тотуны (эксплуатацияләүне) һәм алардан файдалануны финанслау ихтыяҗы буенча фаразларны формалаштыру эшен оештыру;

8.1.52. Башкарма комитетның мәгълүмат һәм телекоммуникация системаларын гамәлгә кертүгә, үстерүгә, шулай ук алардан файдалануга чыгымнарны билгеләү өлешендә җирле бюджетны формалаштыруда, раслауда, үтәүдә катнашу;

8.1.53. мәгълүмат системаларының бердәм реестрын һәм мәгълүмат ресурсларының бердәм реестрын алып баруны оештыру;

8.1.54. Башкарма комитетның мәгълүмати куркынычсызлыгын тәэмин итү, шул исәптән компьютер һөҗүмнәрен ачыклау, кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү эшен оештыру;

8.1.55. мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итү мәсьәләләре буенча Башкарма комитетның структур бүлекчәләре эшчәнлеген координацияләү;

8.1.56. Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының мәгълүмат системаларында шәхси мәгълүматларны эшкәрткәндә, аларны техник яктан саклауны тәэмин итүне контрольдә тоту.

8.2. Башкарма комитет Аппараты җитәкчесе үз вәкаләтләре чикләрендә:

а) башкарма комитет Аппаратының түбәндәге бүлекчәләре эшен координацияли:

- Башкарма комитет Аппаратының хокук идарәсе;

- Башкарма комитет Аппаратының кадрлар сәясәте идарәсе;

- Башкарма комитет Аппаратының эшләр идарәсе;

- Башкарма комитет Аппаратының контроль һәм коррупциягә каршы эш идарәсе;

- Башкарма комитет Аппаратының оештыру идарәсе;

- Башкарма комитет Аппаратының эш башкару идарәсе;

- Башкарма комитет Аппаратының муниципаль архив идарәсе;

- Башкарма комитет Аппаратының җәмәгать куркынычсызлыгы мәсьәләләре һәм хокук саклау органнары белән үзара бәйләнешләр идарәсе;

- Башкарма комитет Аппаратының Башкарма комитет Җитәкчесенең вәкаләтләр башкаруын тәэмин итү бүлеге;

- Башкарма комитет Аппаратының иҗтимагый оешмалар белән үзара бәйләнешләр бүлеге;

- Башкарма комитет Аппаратының финанслар белән тәэмин итү һәм бюджет вәкаләтләрен үтәү бүлеге;

- Башкарма комитет Аппаратының муниципаль сатып алулар өлкәсендә контроль һәм эчке муниципаль финанс контроле бүлеге;

- Башкарма комитет Аппаратының мобилизация идарәсе;

- Башкарма комитет Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлеге;

б) түбәндәгеләрнең эшен координацияли:

- Башкарма комитетның Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе;

- Башкарма комитетның Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе;

в) түбәндәгеләрнең эшен контрольдә тота һәм эшчәнлекләренең нәтиҗәлелек күрсәткечләре үтәлеше өчен җавап бирә:

- Казан шәһәренең «Хуҗалык-транспорт идарәсе» муниципаль казна учреждениесе;

- «Казан шәһәре иҗтимагый үзәге» муниципаль казна учреждениесе;

- «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе;

- «Яңарыш» ярдәм үзәге» муниципаль автоном учреждениесе;

- «Казан шәһәренең конкурентлык сәясәте һәм сатып алулар дирекциясе» муниципаль казна учреждениесе;

- «Казан шәһәренең телекоммуникация технологияләре департаменты» муниципаль бюджет учреждениесе;

- «Шәһәр трансформациясе үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе;

г) үз карамагындагы предприятиеләрнең җитәкчеләрен вазифага билгеләү, алар белән хезмәт килешүләре төзү, үзгәртү, гамәлдән чыгару, аларга карата дисциплинар җәза куллану турында тәкъдимнәр кертә;

д) үз карамагындагы муниципаль учреждениеләр җитәкчеләрен вазифага билгели һәм вазифадан азат итә, аларга карата дисциплинар җәза чараларын куллана, аларның чираттагы елларын һәм командировкаларын килештерә;

е) ведомство карамагындагы учреждение җитәкчеләренең чираттагы елларын һәм командировкаларын килештерә;

ж) түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

- Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты һәм Казан шәһәре районнары буенча хәрби комиссариатлар;

- җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары;

- Башкарма комитет Аппараты вәкаләтләре өлкәсендә муниципаль контрактларны (башка килешүләрне) үтәү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыра торган оешмалар;

з) Башкарма комитет Җитәкчесе йөкләмәсе нигезендә үз эшчәнлеге юнәлеше буенча комиссияләргә җитәкчелек итә, штабларны, эшче төркемнәрне җитәкли, үз вәкаләтләре кысаларында Башкарма комитет Җитәкчесенең башка йөкләмәләрен үти.

8.3. Үз вәкаләтләрен башкару максатыннан Башкарма комитет Аппараты җитәкчесе боерыклар чыгара, шулай ук башка документларны имзалый.

8.4. Башкарма комитет Аппараты җитәкчесе Казан шәһәре җирле үзидарә органнары белән хокук саклау, контроль-күзәтчелек органнары арасындагы хезмәттәшлекне камилләштерү максатыннан чара күрү актлары белән эш алып бару өчен җаваплы зат булып тора.

## IX. Башкарма комитетның район(нар) администрациясе башлыгы вәкаләтләре

9.1. Район(-нар) территориясендә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүне оештыру максатыннан Башкарма комитетның район(-нар) администрациясе башлыгына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

9.1.1. үз вәкаләтләре кысаларында Казан шәһәре бюджетының керем өлешен үтәүне тәэмин итү, салымнарның вакытында түләнмәгән өлешен киметү буенча дәүләт салым хезмәте органнары, башка дәүләт һәм муниципаль органнар белән үзара хезмәттәшлекне оештыру;

9.1.2. район(-нар)ның үсеш планнарын һәм программаларын эшләүне оештыру;

9.1.3. шәһәрнең социаль-икътисади үсеш планнарын әзерләү һәм үтәүне оештыру;

9.1.4. район(-нар)ның муниципаль ихтыяҗлары өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль заказ урнаштыруны оештыру;

9.1.5. район(-нар) территориясендә электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, юынтык сулар чыгаруны оештыру;

9.1.6. район(-нар) территориясендә урнашкан коммуналь хуҗалык объектларын тиешенчә куллануга контрольлек итүне оештыру, су, газ, җылылык һәм энергия белән тәэмин итү объектларының тотрыклы эшен тәэмин итү;

9.1.7. район(-нар) территориясендә муниципаль торак фондын карап тотуны оештыру;

9.1.8. район(-нар) территориясендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү, беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүне оештыру;

9.1.9. район(-нар) территориясен төзекләндерү һәм яшелләндерү эшләрен оештыру;

9.1.10. район(-нар) территориясендә җирләрнең тиешле дәрәҗәдә кулланылышын һәм төзелеш торышын контрольдә тотуны оештыру;

9.1.11. район(-нар) территориясендә Башкарма комитет Аппаратының административ комиссияләре эшчәнлеген оештыру идарәсе эше өчен шартлар тудыру;

9.1.12. муниципаль берәмлекнең мобилизацион әзерлек чараларында катнашуны оештыру һәм билгеләнгән мобилизацион биремнәрне үтәүне тәэмин итү максатыннан Администрацияне мобилизацион әзерләүне башкару;

9.1.13. урамнарда һәм квартал эчендә яктыртуны оештыру, урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр кую;

9.1.14. үз вәкаләтләре кысаларында бүләкләү документларын килештерү;

9.1.15. гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны тәэмин итүне үз вәкаләтләре кысаларында оештыру;

9.1.16. район администрациясенең чыгымнар сметасы нигезендә финанслана торган муниципаль белем бирү учреждениеләре, башка учреждение һәм оешма биналарын һәм корылмаларын карап тотуны тәэмин итүне, алар янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерүне оештыру;

9.1.17. муниципаль милек белән идарә итү буенча муниципаль хокукый актларда каралган функцияләрне башкару, шул исәптән район(-нар) территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан башкару;

9.1.18. район(-нар) территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне, чисталык һәм тәртип тәэмин итүне, җәмәгать транспорты тукталышларын һәм тукталыш павильоннарын карап тотуны контрольдә тотуны оештыру;

9.1.19. район(-нар) территориясендә төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен алу мөмкинлеге булган һәм бушлай

башлангыч гомуми, төп гомуми, урта (тулы) гомуми белем бирүне билгеләнгән тәртиптә оештыру;

9.1.20. район(-нар) территориясендә өстәмә белем һәм һәркем өчен алу мөмкинлеге булган бушлай мәктәпкәчә белем бирүне оештыру, шулай ук каникул вакытында балаларның ялын билгеләнгән тәртиптә оештыру;

9.1.21. гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм очракларда район(-нар) территориясендә теркәлгән балигъ булмаган, эшкә сәләтсез һәм эшкә сәләте чикле гражданнарның законлы вәкилләре тарафыннан аларның милкен (милек хокукларын) алу буенча килешүләр төзүгә рөхсәт бирү турында карар кабул итү;

9.1.22. район(-нар) территориясендә теркәлгән, өйләнешү өчен закон буенча яше тулмаган затларны эмансипацияләү һәм аларга өйләнешергә рөхсәт бирү турында карар кабул итү;

9.1.23. район(-нар) территориясендә теркәлгән, закон белән билгеләнгән тәртиптә кайда булуы билгесез дип танылган гражданнар милке белән ышанычлы идарә итү килешүләрен төзү турында карар кабул итү;

9.1.24. гамәлдәге законнар белән каралган очракларда опека һәм попечительлек билгеләү турында карар кабул итү;

9.1.25. торак урыннарны үзгәртеп планлаштыруга һәм үзгәртеп коруга рөхсәт бирү һәм аларны билгеләнгән тәртиптә файдалануга кертү турында карарлар кабул итү;

9.1.26. Татарстан Республикасы законнары белән расланган Социаль ипотека программасын гамәлгә ашыру кысаларында торак шартларын яхшыртырга теләгән гражданнарны исәпкә алуны, исәптән төшерүне, исәп эшләрен туплауны оештыруда катнашу;

9.1.27. сайлаулар һәм референдумнар, шулай ук дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда халыкның башка формада катнашуын тәэмин итүне оештыру;

9.1.28. Башкарма комитет раслаган исемлек нигезендә төзелеп беткән күчемсез милек объектларын файдалануга тапшыру турында карар кабул итү;

9.1.29. торак урыннарны яшәү өчен яраксыз дип тану, күчемсез милек объектларын сүтү турында билгеләнгән тәртиптә карар кабул итүдә катнашу;

9.1.30. гамәлдәге законнар белән каралган очракларда коллектив һәм хезмәт шартнамәләрен хәбәр итеп теркәүне оештыру;

9.1.31. район(-нар) халкын ягулык белән тәэмин итү чараларын оештыру;

9.1.32. район(-нар) территориясендә милли һәм башка бәйрәмнәр, күргәзмәләр, концерт программалары үткәрүне оештыру;

9.1.33. район(-нар) территориясендә социаль-мәдәни объектлар төзүне стимуллаштыру, район(-нар) территориясендә әлеге объектларны төзү һәм карап тоту турында тәкъдимнәр кертү буенча чаралар күрү;

9.1.34. район(-нар) халкы, инвалидлар, ветераннар арасында физкультура-сәламәтләндерү эшен оештыруда һәм үткәрүдә, физик культура һәм спорт өлкәсендә шәһәр һәм район программаларын гамәлгә ашыру эшен алып баруда ярдәм күрсәтү;

9.1.35. район(-нар) территориясендә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу;

9.1.36. район(-нар) халкын элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте белән тәэмин итүне оештыру;

9.1.37. территориаль иҗтимагый үзидарә үсешенә һәм район(-нар) халкының җирле үзидарә эшчәнлегендә башка формада катнашуына ярдәм итүне оештыру;

9.1.38. район(-нар) территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны оештыру;

9.1.39. ябыла торган предприятиеләргә һәм оешмаларга хезмәт күрсәтү, аларның документларын архивка тапшыруны әзерләүне оештыру;

9.1.40. төзелеп беткән күчемсез милек объектларын кабул итү комиссиясе эшендә катнашу;

9.1.41. законнар нигезендә торак биналарны хосусыйлаштыру процессын оештыру;

9.1.42. район(-нар) территориясендә рекреация зоналары (паркларны, скверларны, пляжларны, табигатьтә оештырыла торган ял итү урыннарын да кертеп, гражданнар ял итә торган урыннар) булдыру һәм аларны карап тоту турында тәкъдимнәр кертү;

9.1.43. район(-нар) территориясендә үз вәкаләтләренә карамаган, шул исәптән ведомствоара характерга ия булган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Казан шәһәре Думасы карарлары проектларын, Башкарма комитет хокукый актларын әзерләүне оештыру һәм раслауга кертү;

9.1.44. район(-нар) халкын кабул итүне оештыру, шулай ук гражданнарның шикаятьләрен, гаризаларын һәм тәкъдимнәрен карап тикшерү, алар буенча үз вәкаләтләре кысаларында кирәкле чаралар күрү;

9.1.45. коррупциягә каршы көрәш чараларын оештыру;

9.1.46. муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын үтәү буенча вәкаләтләрне башкару;

9.1.47. Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, Казан шәһәре территориясендә балаларның юл-транспорт һәлакәтендә травмалар алуын кисәтү чараларын гамәлгә ашыруны да кертеп, үз вәкаләтләре кысаларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүдә катнашу;

9.1.48. шәһәрне төзекләндерүне, килешү нигезендә әлеге эшкә эшмәкәрләрне, предприятиеләрне, учреждениеләрне, оешмаларны, шулай ук халыкны җәлеп итүне оештыруда катнашу;

9.1.49. муниципаль учреждениеләрдә, муниципаль унитар предприятиеләрдә энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру буенча чараларда катнашу, аларны үткәрүне контрольдә тоту;

9.1.50. шәһәр территориясендә җәмәгать эшләрен оештыруда катнашу;

9.1.51. законнар, муниципаль хокукый актлар белән каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

9.1.52. җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын һәм җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзекләндерү элементларын (светофор объектларыннан тыш) ремонтлау һәм карап тоту эшчәнлеген башкаруны, җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзекләндерү элементларын (светофор объектларыннан тыш) капиталь ремонтлауны оештыру;

9.1.53. Казан шәһәре территориясендә милләтара һәм динара татулыкны ныгытуга, милли азчылыкның хокукларын яклауга, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптацияләшүен тәэмин итүгә, милләтара (этникара) низагларны кисәтүгә юнәлтелгән чараларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

9.1.54. җәмәгать транспорты тукталышларын карап тотуны тәэмин итү буенча чаралар күрү;

9.1.55. торак урыннарны торак булмаган урыннар һәм торак булмаган урыннарны торак урыннар итеп үзгәртү турында билгеләнгән тәртиптә карарлар кабул итү;

9.1.56. район(-нар) территориясендә террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтүдә катнашу;

9.1.57. район(-нар) территориясендә террорчылык күренешләре нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү эшендә катнашу;

9.1.58. дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматларның яшеренлек һәм аларны саклау режимы таләпләрен үтәүне тәэмин итү;

9.1.59. дәүләт серенә рөхсәт бирү турында карар кабул иткән җитәкче белән чит илгә чыгуны билгеләнгән тәртиптә килештерү;

9.1.60. кул астында эшләүче хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт серен саклау турындагы законнарның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итү;

9.1.61. администрация хезмәткәрләре белән производствода бәхетсезлек очрагы килеп чыккан вакыттан алып бер тәүлек эчендә гамәлдәге законнар һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән органнарга бу хакта хәбәр итүне тәэмин итү;

9.1.62. каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә экологик тәрбия бирүне оештыруда һәм экологик культура формалаштыруда үз вәкаләтләре чикләрендә катнашу;

9.1.63. каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) булдыру һәм карап тоту (Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән, мондый бурыч башка затларга йөкләнгән очраклардан тыш).

## X. Башкарма комитетның «Иске шәһәр» территориясе префекты вәкаләтләре

10.1. Билгеләнгән территориядә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүне оештыру максатыннан Башкарма комитетның «Иске шәһәр» территориясе префектына түбәндәге вәкаләтләр йөкләнә:

10.1.1. билгеләнгән территория чикләрендә шәһәр округы милкендә булган мәдәни мирас объектларын саклауны, файдалануны һәм популярлаштыруны тәэмин итү;

10.1.2. җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын ачыклау, исәпкә алу, өйрәнү, аларның җимерелүен яки билгеләнгән территория чикләрендә аларга зыян китерүне булдырмау буенча үз вәкаләтләре кысаларында чаралар күрү;

10.1.3. билгеләнгән территория чикләрендә 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләр) турында»гы федераль закон нигезендә җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын саклауны һәм файдалануны контрольдә тоту;

10.1.4. билгеләнгән территория чикләрендә урнашкан мәдәни мирас объектларын Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләрнең) бердәм дәүләт реестрына кертү яки аларны әлеге реестрдан төшереп калдыру, шулай ук киләчәктә үзгәртеп корып һәм заманча файдалануга җайлаштырып сакланырга тиешле тарихи яктан

кыйммәтле, шәһәр формалаштыра торган объектлар исемлегенә кертү турында тиешле органнарга тәкъдимнәр кертү;

10.1.5. билгеләнгән территория чикләрендә урнашкан җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын оештыруда һәм саклауда катнашу, әлеге объектларның исемлеген алып бару;

10.1.6. билгеләнгән территория чикләрендә муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларында мәгълүмати язулар һәм тамгалар урнаштыруны тәэмин итү;

10.1.7. билгеләнгән территория чикләрендә 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон таләпләре нигезендә җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын карап тотуны һәм файдалануны тәэмин итә торган чаралар каралырга тиешле шәһәр төзелеше регламентларын эшләүне контрольдә тотуда катнашу;

10.1.8. 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон белән билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә Башкарма комитетның җир кишәрлекләрен бирү һәм аларның хокукый режимын үзгәртү турындагы карар проектларын килештерү, шулай ук билгеләнгән территория чикләрендә урнаштырыла торган (урнашкан) объектларга карата әлеге акт проектларына тиешле график һәм текст материалларын әзерләүдә катнашу;

10.1.9. билгеләнгән территория чикләрендә 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында»гы федераль закон белән каралган очракларда һәм тәртиптә җир төзелеше, җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык һәм башка эшләр башкаруны, әлеге эшләрне башкару проектларын килештерү;

10.1.10. мәдәни мирас объектын саклау буенча эшләр башкаруга йөкләмә һәм җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектын саклау эшләрен башкаруга рөхсәт әзерләү, шулай ук билгеләнгән территория чикләрендә муниципаль хокукый акт нигезендә билгеләнгән тәртиптә мәдәни мирас объектын саклау эшләрен башкаруга проект документларын килештерү;

10.1.11. билгеләнгән территория чикләрендә җирле (муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларына карата мәдәни мирас объекты хуҗасының сак йөкләмәсен әзерләү;

10.1.12. билгеләнгән территория чикләрендә шәһәр милкендә булган мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану һәм популярлаштыру, җирле

(муниципаль) әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү максатыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен, шулай ук үз ихтыяҗлары өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә контрактлар төзү буенча муниципаль заказ бирүче сыйфатында чыгыш ясау;

10.1.13. билгеләнгән территория чикләрендә гражданлык законнары нигезендә үз вәкаләтләрен башкару максатыннан конкурслар үткәрүне (шул исәптән ачык конкурслар үткәрүне) оештыру;

10.1.14. билгеләнгән территория чикләрендә инженерлык, транспорт һәм социаль инфраструктура үсеше схемаларын һәм проектларын карап тикшерүдә һәм килештерүдә катнашу;

10.1.15. территориаль яктан планлаштыру документларына, Казан шәһәрендә төзелгән биналарның тышкы архитектура күренешенә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре), аларны саклау һәм билгеләнгән территория чикләрендә урнаштырыла торган (урнашкан) объектларга карата файдалану турындагы законнар таләпләренә туры килү-килмәү өлешендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру урынын һәм тышкы күренешен билгеләнгән тәртиптә килештерүдә катнашу;

10.1.16. билгеләнгән территория чикләрендә урнашкан (урнаштырыла торган) объектларга карата территориаль планлаштыру яки территорияне планлаштыру турындагы документлар нигезендә төзелеш өчен һәм булган биналарны реконструкцияләү өчен җир кишәрлекләре сайлауда катнашу;

10.1.17. билгеләнгән тәртиптә сатуларга (аукционнарга) куела торган җир кишәрлекләрен формалаштыруда һәм билгеләнгән территория чикләрендә сатуларны (аукционнарны) үткәрү шартларын билгеләүдә катнашу;

10.1.18. билгеләнгән территория чикләрендә билгеләнгән тәртип нигезендә объектларны урнаштыру урыннарын беренчел килештерүдә катнашу;

10.1.19. Башкарма комитетка билгеләнгән территория чикләрендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен резервлау һәм мәҗбүри алу, шул исәптән сатып алу юлы белән мәҗбүри алу турында тәкъдимнәр кертү;

10.1.20. билгеләнгән территория чикләрендә урнашкан объектларга карата капиталь төзелеш объектларына рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү турында яки, мондый карарның сәбәпләрен күрсәтеп, әлеге рөхсәтне бирүне кире кагу турында Башкарма комитетның хокукый актлары проектларын әзерләүдә катнашу;

10.1.21. билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлек иткәндә, мәдәни мирас объектлары хуҗаларына һәм алардан файдаланучыларга ярдәм күрсәтү;

10.1.22. билгеләнгән территория чикләрендә объектларны төзү (реконструкцияләү) мәсьәләләре буенча муниципаль заказ формалаштыруда катнашу;

10.1.23. билгеләнгән территория чикләрендә инвалидлар өчен социаль инфраструктура объектларыннан тоткарлыксыз файдалану шартларын булдыруда катнашу;

10.1.24. муниципаль контрактлар төземичә гамәлгә ашырыла торган сатып алулар реестрын алып бару;

10.1.25. Башкарма комитетның «Иске шәһәр» префектурасы вәкаләтләренә бәйле бәхәсләр буенча судларда катнашуны тәэмин итү, шул исәптән Башкарма комитет исеменнән дә судларда катнашуны тәэмин итү;

10.1.26. Казан шәһәре территориясендә тиешле административ регламент тарафыннан билгеләнә торган муниципаль хокукый актлар таләпләренең үтәлешенә муниципаль контрольне 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында»гы федераль закон нигезендә гамәлгә ашыру;

10.1.27. билгеләнгән территория чикләрендә террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтүдә катнашу;

10.1.28. билгеләнгән территория чикләрендә террорчылык күренешләре нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү эшендә катнашу;

10.1.29. дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматларның яшеренлек һәм аларны саклау режимы таләпләрен үтәүне тәэмин итү;

10.1.30. дәүләт серенә рөхсәт бирү турында карар кабул иткән җитәкче белән чит илгә чыгуны билгеләнгән тәртиптә килештерү;

10.1.31. кул астында эшләүче хезмәткәрләрнең дәүләт серен саклау турындагы законнарны үтәвен контрольдә тотуны тәэмин итү;

10.1.32. префектура хезмәткәрләре белән производствода бәхетсезлек очрагы килеп чыккан вакыттан алып бер тәүлек эчендә гамәлдәге законнар һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән органнарга бу хакта хәбәр итүне тәэмин итү;

10.1.33. Тарихи-мәдәни территорияне үстерү буенча «Тарихи мохит» муниципаль бюджет учреждениесе эшендә оештыру ягыннан, матди-техник һәм мәгълүмати яктан ярдәм күрсәтү;

10.1.34. Тарихи-мәдәни территорияне үстерү буенча «Тарихи мохит» муниципаль бюджет учреждениесе өчен муниципаль йөкләмә формалаштыру һәм раслау турында карарлар кабул итү;

10.1.35. Тарихи-мәдәни территорияне үстерү буенча «Тарихи мохит» муниципаль бюджет учреждениесе структурасын килештерүдә катнашу.

10.2. Башкарма комитетның «Иске шәһәр» территориясе префекты үз вәкаләтләре кысаларында «Тарихи мохит» тарихи-мәдәни территориясен үстерү буенча муниципаль бюджет учреждениесе эшен контрольдә тота һәм аның эшчәнлегенең нәтиҗәлелек күрсәткечләрен үтәү өчен җавап бирә, аның җитәкчесен вазифага билгели һәм вазифасыннан азат итә, аңа карата дисциплинар җәза чараларын куллана, аның ялын һәм командировкаларын килештерә; үз карамагындагы учреждение җитәкчесе урынбасарларын вазифага билгеләүне һәм вазифадан азат итүне килештерә.

## XI. Башкарма комитет органнары җитәкчеләренең вәкаләтләре

11.1. Башкарма комитет органы вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүне оештыру максатыннан әлеге орган җитәкчесе:

11.1.1. орган исеменнән ышанычнамәсез эш итә, хакимият органнарында, оешмаларда, учреждениеләрдә, предприятиеләрдә аның мәнфәгатьләрен яклый;

11.1.2. законнар, Башкарма комитет органы турында нигезләмә, башка муниципаль хокукый актлар, милекне беркетү турында контракт һәм шартнамә белән билгеләнгән чикләрдә орган исеменнән килешүләр төзи, ышанычнамәләр бирә, башка гамәлләр кыла;

11.1.3. бүлеп бирелгән ассигнованиеләр кысаларында органның штат расписаниесен Башкарма комитет Җитәкчесенә раслауга кертә;

11.1.4. үз вәкаләтләре кысаларында барлык хезмәткәрләр һәм башка затлар өчен үтәү мәҗбүри булган боерыклар чыгара;

11.1.5. эш бирүче буларак, муниципаль хезмәткәрләргә карата барлык вәкаләтләрен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра, шулай ук орган хезмәткәрләрен вазифага билгели һәм вазифадан азат итә, аларга карата законнар нигезендә дисциплинар җәза һәм бүләкләү чараларын куллана;

11.1.6. исәп-хисапның торышы, хисапларны, шул исәптән бухгалтерлык һәм статистика хисапларын билгеләнгән формалар буенча тиешле органнарга үз вакытында һәм тулысынча тапшыру өчен җавап бирә;

11.1.7. үзе җитәкләгән орган вәкаләтләренә кертелгән мәсьәләләр буенча муниципаль хезмәтләрне турыдан-туры башкаручы булып тора;

11.1.8. орган вәкаләтләренә караган мәсьәләләр буенча муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу өчен сәбәпләр булган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне кире кагу турында карарлар кабул итә;

11.1.9. үзе җитәкләгән Башкарма комитет органы турындагы нигезләмәдә күрсәтелгән һәм гамәлдәге законнарга каршы килми торган башка функцияләрне башкара;

11.1.10. террорчылыкны һәм экстремизмны кисәтүдә катнаша;

11.1.11. террорчылык күренешләре нәтиҗәләрен киметү һәм (яки) бетерү эшендә катнаша;

11.1.12.дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматларның яшеренлек һәм аларны саклау режимы таләпләрен үтәүне тәэмин итү;

11.1.13. дәүләт серенә рөхсәт бирү турында карар кабул иткән җитәкче белән чит илгә чыгуны билгеләнгән тәртиптә килештерә;

11.1.14. кул астында эшләүче хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт серен саклау турындагы законнарның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итә;

11.1.15. Башкарма комитет органы хезмәткәрләре белән производствода бәхетсезлек очрагы килеп чыккан вакыттан алып бер тәүлек эчендә гамәлдәге законнар һәм муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән органнарга бу хакта хәбәр итүне тәэмин итә.